С (Башҡ)
Н93

НАЖАР НӘЖМИ

Һиңә барам

131027



С (Башк)
Н93

НАҖАР НӘҖМИ

Сиңа барам

Шигырьләр һәм поэмалар

КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1988

ББҚ 84(2Р-Баш)-5
Н98

Рецензенты
РАВИЛ ФАЙЗУЛЛИН

Нәҗми Нажар

Н98 Сиңа барам: Шигырьләр һәм поэмалар.— Қазан: Тат. кит. нәшр., 1988.— 144 бит.

Башкортстанның халык шагыйре, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нажар Нәҗминең бу китабына туган ил, туган халкы турындагы уйлануларын, тормыш кичерешләрен чагылдырган шигырьләре һәм поэмалары тупланды.

Н $\frac{4702511000-074}{М132(03)-88}$ 165—88 ББҚ 84(2Р-Баш)-5

131027

© Татарстан китап нәшрияты, 1988

Баш. республиканская библиотека им. Н. К. Крупской
09

МОҢНАР ШАГЫЙРЕ

Нажар Нәҗми беренче чиратта фәлсәфи-лирик шигырьләр һәм поэмалар шагыйре. Шулай да сүзне җырлардан, моңнардан башлап китәсе килә, чөнки шагыйрьнең бөтен иҗаты халкыбызның рухи яшәеше, рухи сулышы өчен гаять зарури булган киң колачлы моң белән сугарылган. Без радио-телевидениедән һәм яраткан артистларыбыз концертларында Нажар Нәҗми шигырьләренә язылган җырларны көтеп алабыз, ялгыз калган моңсу чакларыбызда һәм күңелле мәҗлесләрдә аларны җырлап йөрибез. «Уфа юкәләре» «Юкка түгелдер», «Сиңа тагын мин бер киләм әле» кебек җырлар безнең күңелләргә халкыбыз җырлары кебек үк тирән кереп урнашты.

Җыр-моң... шигырь-моң... поэма-моң... Гаҗәп, без һәрвакыт «моң-моң» дибез, ләкин бу сүзнең төп-төгәл генә нәрсәне аңлатканын, йә булмаса аның башка телләргә тәрҗемәсен әле бүген дә таба алганыбыз юк. Сүзлекләребездә шушы гап-гади сүзне аңлату өчен озын-озын мәкаләләр язып, төрле-төрле вариантлар тәкъдим итеп карыйбыз, әмма бу үтә дә серле, тылсымлы, ниндидер магик көчкә ия булган сүзнең мәгънәсен төгәл генә әйтә алмыйбыз. Әйтә алмыйбыз, әмма тоябыз. Чөнки моңның төгәл мәгънәсен җыр әйтә, шигырь әйтә. Нажар Нәҗми — әнә шул «моң»ның төгәл мәгънәсен әйтә алучы җырлар, шигырьләр, поэмалар иҗат итүче бәхетле шагыйрь ул.

Чынбарлыкка мөнәсәбәтендә Нажар Нәҗми дөньяны, тормышны яратучы шагыйрь. Ул күп әсәрләрендә Россиягә, туган Башкортстанына, таулар иле Дагстанга, Украинага, илебезнең башка төбәкләренә, шул исәптән Татарстанга да җылы хисләр белән мөрәҗәгать итә. «Татар теле», «Париж өстендә», «Бар!», «Булгандыр бит», «Чит тел аша» һәм башка күп кенә шигырьләрендә һәм поэмаларында шагыйрь үзенең ватандарлык, мәхәббәт, җаваплылык, борчылу хисләрен калку поэтик чаралар белән тасвирлый. Бу әсәрләрдә нәрсәгә дә булса икеләнүнең, турысын әйтүдән тыелуның эзе дә юк. Шагыйрь үз сүзен шагыйрьләрчә ап-ачык, саллы итеп әйтә.

Гомумән, Нажар Нәҗминең байтак әсәре татар халкы тарихы, аның язмышы һәм бүгенге көне белән тыгыз бәйләнгән. Бу җәһәттән «Иблис» поэмасы аерым бер әһәмияткә ия. Шигъри яктан гаять экспрессив, жанр ягыннан романнарга торырлык бу әсәрдә проблемалар заманча кыю куелган, геройлар чын әдәби образлар дәрәҗәсенә

ББҚ 84 (2Р-Баш) -5
Н98

Рецензенты
РАВИЛ ФАЙЗУЛЛИН

Нәҗми Нажар

Н98 Сиңа барам: Шигырьләр һәм поэмалар.— Қазан: Тат. кит. нәшр., 1988.— 144 бит.

Башкортстанның халык шагыйре, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нажар Нәҗминең бу китабына туган ил, туган халкы турындагы уйлануларын, тормыш кичерешләрен чагылдырган шигырьләре һәм поэмалары тупланды.

Н $\frac{4702511000-074}{М132(03)-88}$ 165—88 ББҚ 84(2Р-Баш)-5

131027

© Татарстан китап нәшрияты, 1988

Баш. республиканская библиотека им. Н. К. Крупской

МОҢНАР ШАГЫЙРЕ

Нажар Нәжми беренче чиратта фәлсәфи-лирик шигырьләр һәм поэмалар шагыйре. Шулай да сүзне җырлардан, моңнардан башлап китәсе килә, чөнки шагыйрьнең бөтен иҗаты халкыбызның рухи яшәеше, рухи сулышы өчен гаять зарури булган киң колачлы моң белән сугарылган. Без радио-телевидениедән һәм яраткан артистларыбыз концертларында Нажар Нәжми шигырьләренә язылган җырларны көтеп алабыз, ялгыз калган моңсу чакларыбызда һәм күңелле мәҗлесләрдә аларны җырлап йөрибез. «Уфа юкәләре» «Юкка түгелдер», «Сиңа тагын мин бер киләм әле» кебек җырлар безнең күңелләргә халкыбыз җырлары кебек үк тирән кереп урнашты.

Җыр-моң... шигырь-моң... поэма-моң... Гаҗәп, без һәрвакыт «моң-моң» дибез, ләкин бу сүзнең төп-төгәл генә нәрсәне аңлатканын, йә булмаса аның башка телләргә тәрҗемәсен әле бүген дә таба алганыбыз юк. Сүзлекләребездә шушы гап-гади сүзне аңлату өчен озын-озын мәкаләләр язып, төрле-төрле вариантлар тәкъдим итеп карыйбыз, әмма бу үтә дә серле, тылсымлы, ниндидер магик көчкә ия булган сүзнең мәгънәсен төгәл генә әйтә алмыйбыз. Әйтә алмыйбыз, әмма тоябыз. Чөнки моңның төгәл мәгънәсен җыр әйтә, шигырь әйтә. Нажар Нәжми — әнә шул «моң»ның төгәл мәгънәсен әйтә алучы җырлар, шигырьләр, поэмалар иҗат итүче бәхетле шагыйрь ул.

Чынбарлыкка мөнәсәбәтендә Нажар Нәжми дөньяны, тормышны яратучы шагыйрь. Ул күп әсәрләрендә Россиягә, туган Башкортстанына, таулар иле Дагстанга, Украинага, илебезнең башка төбәкләренә, шул исәптән Татарстанга да җылы хисләр белән мөрәҗәгать итә. «Татар теле», «Париж өстендә», «Бар!», «Булгандыр бит», «Чит тел аша» һәм башка күп кенә шигырьләрендә һәм поэмаларында шагыйрь үзенең ватандарлык, мәхәббәт, җаваплылык, борчылу хисләрен калку поэтик чаралар белән тасвирлый. Бу әсәрләрдә нәрсәгә дә булса икеләнүнең, турысын әйтүдән тыелуның эзе дә юк. Шагыйрь үз сүзен шагыйрьләрчә ап-ачык, саллы итеп әйтә.

Гомумән, Нажар Нәжминең байтак әсәре татар халкы тарихы, аның язмышы һәм бүгенге көне белән тыгыз бәйләнгән. Бу җәһәттән «Иблис» поэмасы аерым бер әһәмияткә ия. Шигъри яктан гаять экспрессив, жанр ягыннан романнарга торырлык бу әсәрдә проблемалар заманча кыю куелган, геройлар чын әдәби образлар дәрәҗәсенә

күтәрелгән, катлаулы сюжет һәм композиция камил эшләнгән. Татар халкының тарихи яссылыктагы киң планлы гомуми образын югары әдәби һәм сәнгати чаралар белән сурәтләү ягыннан караганда «Иблис» поэмасы Тукай шигырьләре, М. Галәүнең «Мөһаҗирләр» һәм Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романнары, Такташның «Җир уллары» трагедиясе, Туфан әсәрләре белән янәшә бара.

Тормышта гаять көләч, шат күңелле, сабыйларча яңгыравык көлүе белән әңгәмәдәшләрен дә үз кәефенә ияртә торган Нәҗар Нәҗминең шигырь бәйләмнәрен, шигырь китапларын укый башласаң, шигырьдән шигырьгә, поэмадан поэмага күчеп барган ниндидер олы, вакланмаучы, илаһи трагизмга юлыгасың. Юк, бу — чарасыз, пессимистик, адәм баласының рухи бәләкәйләнүенә алып килә торган трагизм яки елау-сыктау түгел. Нәҗар Нәҗми трагизмы ул аяусыз рәвештә дөреслекне, хаклыкны даулаучы, киләчәкне «иблислек»тән чистартырга омтылучы трагизм. Әгәр миңа бу фикерне раслау өчен шагыйрь иҗатыннан аерым мисаллар, шигырь юллары китерергә кушсалар, миңа шул ук «Иблис» поэмасын тулысынча кабатлап чыгарга, «Алаша», «Туры килгәч язмыш язмышка», «Ике таш», «Икмәк һәм шәрап», «Янган йорт», «Васыять» һәм тагын әллә никадәр шигырьне күчереп язарга туры килер иде. Ләкин мондый кабатлаулардан мине шагыйрь үзе коткара — укучы кулында аның китабы, аңа әлеге әсәрләрнең барысы да тупланган. Бу китаптагы вазифам буенча миңа хөрмәтле укучыны күренекле шагыйрь Нәҗар Нәҗминең моңнар дөньясына чакырырга гына кала.

ГӘРӘЙ РӘХИМ
сентябрь, 1987 ел

АВЫЛ КӨЕ

Авыл көе... Бар бит шундый көйләр!..
Чыңлый-чыңлый гармун телендә,
Еллар аша гасырларны ярып,
Яңгырый әле ул көй бүген дә.

Авыл көе... Димәк авылныкы!
Үз туфраклы, җирле, үз илле!
Ул табигый — җир астыннан бәреп
Чыккан гади чишмә шикелле.

Авыл көе... Ата-бабам көе...
Җүңелләргә кергән күңелдән.
Җир теле һәм җир акылы белән
Йөрәк моңына килеп үрелгән.

Авыл көе... Мине үстергән көй,
Минем гади, моңлы төбәгем.
Гомеремне, кулдан килгән кадәр,
Шушы гади көйдә көйләдем.

СИНЕҢ НИНДИ УЛЫҢМЫН МИН?

Бөтенесе синнән килә миңа,
Бар булмышым синнән, бар моңым.
Әниемнең күз карашы кебек
Бөтен төсең, бөтен барлыгың.
Туган илем, туган җирем,
Синең нинди улыңмын мин?
Шуны беләм: син яшьнәсәң әгәр,
Очкыныңда булырмын мин.

Матурлыгың синең, бар сафлыгың
Йөрәгемә кереп үрелгән.
Алар миңа ана сөте белән,
Ана теле белән бирелгән.
Туган илем, туган җирем,
Синең нинди улыңмын мин?
Шуны беләм: син күкрәсәң әгәр,
Күкрәвеңдә булырмын мин.

Синең исемең бар нәрсәдән өстен,
Һәр авазың — миңа бер гомер,
Шулардан да әгәр мәхрүм булсаң,
Яшәүләрең яшәү түгелдер.
Туган җирем, туган илем,
Синең нинди улыңмын мин?
Шуны беләм: яралана калсаң,
Кан тамчыңда булырмын мин.

СИҢА БАРАМ

Таныш түгел сиңа барыр юлым,
Һәр адымың сергә күмелгән.
Якынсың да, ераксың да төсле,
Шикләнүләр китми күңелдән.
Гомер буе сиңа барам,
Йөрәгеңә юллар салам.
Шул юллардан үтәр өчен,
Хыялыма җитәр өчен,
Сиңа барам, сиңа барам.
Озын кебек — таныш түгел юллар,—
Түземлекләр кирәк үткәндә.
Ничә барма, мин тәү үтәм төсле,
Киләчәктән үтәм үткәнгә.
Гомер буе сиңа барам,
Йөрәгеңә юллар салам.
Шул юллардан үтәр өчен
Хыялыма җитәр өчен
Сиңа барам, сиңа барам.

БЕР ГОМЕР ҖИТМИ ИКӘН

Шатлыклардан, кайгылардан
Торган гомерем минем,
Алтын капкаларың ачып,
Мин керер кебек идем.
Дөнья юмарт күренсә дә,
Күпне өмет итмә икән.
Күпкә түгел, азына да
Бер гомер җитми икән.

Елларны юлларга үреп,
Үземчә гомер сөрдем.
Матур илләр, матур җирләр
Күрмәдем түгел, күрдем.

Туган җирем, ят матурлык
Каныңа сеңми икән.
Канга сеңгәнне җырларга
Бер гомер җитми икән.

Туйдырган чагы да булды —
Күңелнең кайткан чагы.
Безнең сөюдән дә калыр
Тормышның алачагы.
Җанкай-җанаш, җан чишмәсе
Ул корып бетми икән.
Сине туйганчы сөяргә
Бер гомер җитми икән.

ЯШЕЛ КӨЗ

Һәр мизгелнең бар үз төсе, нуры...
Көзләргә хас шигъри алтын төс.
Быел да көз килде менә... Килде!
Әмма бу көз яшел-яшел көз.
Башка җирдә көз көз төсендәдер,
Тик бер төстән тормый җир йөзе.
Быелгы көз хас тик шушы җиргә,
Җир-төякнең генә бер көзе.
Иртә-кичен салкын, кырау-томан...
Менә-менә явар кырпак кар.
Әмма яшел әле урман, болын —
Җиргә коела яшел яфраклар.
Бер карасаң, нинди сәер күренеш —
Табигый түгел хәтта табигать.
(Боларны мин уйлап чыгармадым,
Ышанмагыз миңа, җәмәгать!)
Миндә дә шул хәзер көзнең соңы,
Яварга гына тора кырпак кар.
Әмма көзем һаман яшел көе,
Яшел көе коела яфраклар.

КАЙДА БУЛДЫМ?..

Акыл өләшкәндә, өй артында калган.

Әни сүзләре

Кайда булдым, кайда йөрдем,
Мәңгелек тын серләшкәндә?
Туганмын — өйдә булганмын,
Җирдә гомер өләшкәндә.

Гомер — ул бер сайраган кош —
Очып килә, очып китә,
Өлешкә тигән елларның
Көмеш кылын чиртә-чиртә.

Көмеш кыллар — кыска еллар
Алтыннарга тиңләшкәндә,
Кайда булдым мин, матурлык
Һәм олпатлык өләшкәндә?

Кайда булдым яшьлек сөю
Телләрендә сөйләшкәндә?
Булдым сафта — афәт килгәч —
Илдә мылтык өләшкәндә.

Булдым өйдә — яхшылыклар
Яман белән алышканда.
Чыктым өйдән — булдыксызлар
Дан артыннан чабышканда.

Үзем булдым булганынча,
Ә булганы артмады һич.
Булмаганны бар димәдем,
Дан-шөһрәткә китмәде ис.

Акылым да, ялкыным да
Булган кадәр... Үзем белән.
Яхшылыкка, матурлыкка
Табындым мин шигырь белән.

Мин сер бирмәм, мәңгелектән
Билгесезлек җилгәндә дә.
Беләмен: өйдә булырмын,
Миңа әҗәл килгәндә дә.

УФА ЮКӘЛӘРЕ

Яшьлек урамнары...
Тулы хыяллары...
Без шатлыкка туймас исәрләр.
Уфа юкәләре
Безнең хакта да әле
Яфрак яра-яра сөйләрләр.

Безнең менгән атлар,
Еллар — аргамаклар,
Көмеш тезген, алтын йөгәннәр.
Уфа юкәләре
Безнең хакта да әле
Чәчкә ата-ата сөйләрләр.

Гомер ике килми,
Утлар ике сүнми,
Без мең янып, тик бер сүнгәннәр.
Уфа юкәләре
Онытмаслар әле —
Яфрак коя-коя сөйләрләр.

* * *

Көз. Төн. Яңгыр. Яңгыр да җил...
Бар тантанаң шулмы, көзем?
Яңгыр да җил... Тирә-якта
Беркем дә юк — мин берүзем.
Тәрәз аша якты төшә —
Каеннар ялт ап-ак, юеш.
Бу җилдә соң кем шауласын?
Алар шаулый... Шулай тиеш.
Миңа рәхәт! Беркемне дә
Чакыру юк: «Кил,— диеп,— кил!»
Бу минутта мин бит үзем
Көз, төн, яңгыр... Яңгыр да җил.

ИМӘН ТӨБЕНДӘ

Күңелдәге шигъри уйлар кинәт
Өзелгәндәй булды зың итеп,
Килеп төшкәч имән чикләвеге
Асфальт-таш өстенә зыңк итеп.

Әй, яшәүнең гади мәганәсе!
Чикләвектән үсә имәннәр.
Ә чәчәкләр җиргә орлык коя,
Үләннәрдән кала үләннәр.

Кешеләрдән җирдә кеше кала,
Заман кала... Заман — ул кеше.
Матурлыклар кала... Кала иман
Һәм идеал — заман җимеше.

Алтын мизгел менә... Җилләр генә
Йөри төсле бүген биләмдә.
Ә мин карап торам чикләвеген
Таш өстенә койган имәнгә.

ЯЗ ТӨСЕНДӘ

Тик өч төстән тора кебек гомер,
Шул өч төскә сыя барысы:
Туган җирдә — җәйнең яшеллеге,
Кыш аклыгы, көзнең сарысы.

Ә яз нинди? Яз ул ала-кола...
Язның төсе төрле чамада:
Кышка авыр киту, җәйгә — килү,—
Алыш бара ике арада.

Мин яз төсендәмен бүген дә —
Ташкыннар һәм алыш көнендә...

* * *

Гомер башы тәүге кардай саф, ак,
Язгы яфрак кебек ямь-яшел.
(Гаҗәеп хәл: ә бит язын, көзен
Сирәк була күкрәү һәм яшен.

Күкрәүләр күп җир чәчәктә чакта,
Өлгергәндә җәен һәр нәрсә,
Гомер җәе дә бит күкрәү мәле.
Яшьнәүләрдә күпме мәгънә!)

Бөтен нәрсә вакыт кәүсәсеннән
Авыр куба, авыр суела.
Кар да язын кара көеп эри,
Сары көеп яфрак коела.

* * *

Рәхәт миңа ялгыз йөрүләре...
Урам... урман... басу юллары.
Хәл ала тән, керә күңелгә җан,
Үз юлына керә уйларым.

Рәхәт миңа ялгыз йөрүләре...
Үз юлында теләк, хыяллар.
Мин азатмын төрле гайбәтләрдән,
Таралалар ялган томаннар.

Рәхәт миңа ялгыз йөрүләре —
Мине кошлар, моңнар ураткан.
Онытыла җәбер, онытыла мыскыл,
Төрле ваклык йөри еракта.

Шигырь белән җитәкләшкән бары
Минем күңел, минем барлыгым.
Тоям шунда бу дөньяда әле
Кирәклегемнең дә барлыгын...

Рәхәт миңа ялгыз йөрүләре...

КҮК ЧӘЧКӘЛӘР

Җәйге басу юлы. Китеп барам...
Бар җир, бар күк июнь төсендә.
Күрәм менә — күк чәчәкләр үскән
Юл өстендә, арыш эчендә...

Юлдагылар хәле юлдагыча,—
Чәчкәләргә барам күз салып,—
Тузан баскан... Кемдер таптап үткән...
Дегеткә дә калган буялып.

Әнә, арыш арасындагылар
Нинди саф һәм күктән-күк кенә.
Ә шулай да арыш өчен алар
Бер чүп кенә, матур чүп кенә.

Гомер буе мин юлдамын —
Юлдагыча бөтен булганым.

ТУУ

Туу авыр... Елап туа бала,
Газаплана, диләр, аналар.
Һәрбер туу шул көенчә калмый —
Яңара һәм үсә баралар.

Күргәнем бар утлы мартеннарның
Ыңгырашып, гүләп торганын.
Ул күрсәтә, димәк, корычның да
Газапланып, кайнап туганын.

Ракеталар күккә ашкан чакта
Җирнең гүләп, тетрәп торуы —
Түгелмени безнең күз алдында
Космик гасырларның тууы?!

Һәр тууның көне, сәгате бар —
Үз вакыты, димәк, үз даны.
Бар аларның җанны тетрәткәне,
Тетрәткәне хәтта дөньяны.

Без яу чаптык... Җанда, тәндә калды
Аның яман утлы ярасы.
Мең газапта туды Ил-ананың
Җиңү дигән батыр баласы.

ИКМӘК ҺӘМ ШӘРАП

Һәр икмәкнең туган басуы бар,
Туган җирле, димәк, иген дә.
Мин игенче улы. Иген игү
Авырлыгын тойдым үзем дә.

Белмимен мин, авырдырмы, юкмы
Үстерүе йөзем җимешен.
Һәрбер шәрап әйтеп тора менә
Җимеш үскән җирнең исемен.

Нилектән ул? Иген үскән җир дә
Шундый юмарт, ямьле исемле,
Тик икмәктә шул җир исеме юк,
Шәрапларда булган шикелле.

Табыннарның йөзек кашы — шәрап
Кешеләргә кәеф өләшә.
Икмәк исә шунда шәрап белән
Тыйнак кына тора янәшә.

Тыйнаклыкта бөеклек бар, диләр,
Онытмыек шуны, димәк, без.
Шәрапсыз бит иген игеп була,
Шәрап эшләп кара икмәксез.

(Солдатлар да тыйнак. Яу кырында
Алар йөзек кашы түгелләр.
Ләкин шунда солдатлардан башка
Булганмы соң җиңү, җиңүләр?!)

Икмәк — гомер! Ул кан тибешендә,
Ул хезмәт һәм бәйрәм төсендә.
Башка нинди исем кушу кирәк
«Икмәк» дигән бөек исемгә.

ПЛАЩ-ПАЛАТКА

Сугышларда кигән әйберләрне
Я ташладым мин, я югалттым.
Плащ-палатка! Яудан син бердәнбер
Сакланып та калган комарткым.

Окопларда яки походларда
Җил-яңгырда сине ябындым.
Тере шаһиты син ут эчендә
Тере калган солдат чагымның.

...Бүген менә көннәр салкынайды,
Иртән кырау төшәр, мөгаен.
Кичен сине чәчәкләргә яптым
(Бик холыксыз быел май ае).

Чәчәкләргә яптым... Моңсу уйлар
Урап алды мине.
Сине ябынганда минем дә бит
Чәчәк чагым иде.

СИН ГОМЕРГӘ ЯШЬТӘШ

Җәмәгатемә

Син яшьтәшсең тәүге шигыремә —
Тәүге адым, тәүге шатлыгыма.
Күпме ел һәм күпме юл үтелгән,
Әйләнгәнче син иң якыныма.

Тилелеген саклап калган яшьлек,
Кыз булып син үсеп өлгергәнче.
Сине көтеп үткән төсле гомер,
Соңгы өмет тәмам өзелгәнче.

О, ул язмыш! Безгә бәхете дә,
Бәхетсезлеге дә бергә килде.
Кем кемне, дип көрәште җан, холык —
Үз-үзеңне, ярый, җиңү җиңде.

Безне, әйе, читләп үтмәде — юк! —
Тормышның ят, вакчыл бураннары.
Ә бармы соң айлар һәм елларның
Шул бурансыз, тыныч торганнары?!

Кагылмады тормыш бизмәненең
Безгә төрле ялган үлчәүләре:
Бер-береңне алдаудан да яман
Үз-үзеңне алдап яшәүләре.

Дусларыма — син дус, дошманнарга
Син аяусыз булдың миннән яман.
Мин үлгәч тә, сиңа җиңел булмас,
Мин бит синдә — мин синдә дә калам.

Күпме ел һәм күпме юл үтелгән,
Әйләнгәнче син иң якыныма.
Хәзер инде син гомергә яшьтәш
Бар җырыма, кайгы, шатлыгыма.

* * *

Дусларым бар... Бар аларның
Искеләре, яңалары...
Өскә яуганда тормышның
Бозлары һәм яңгырлары,
Җанны өтеп, җанны тетеп
Чаккан чакта төрле һурнак *,

* Башкортча: чит умартадан бал урлаучы бал корты.

131027
Библиотека им. Н. К. Крупской

Томра көннәрдә агачка
Ышыкланып торган сымак,
Ышыкландым дусларыма,
Ышыкландым җырларыма...

Бүген дә ут яудыралар —
«Дуслар» уяу, «дуслар» исле...
Ә мин яфраксыз агачка
Ышыкланып торам төсле.

БҮДӘНӘ БЕЛӘН ТАРТАЙ

(Мәсәл түгел)

Бер ел бүдәнә симерсә,
Бер ел — тартай, дигәннәр.
Акыллылар яшәүнең бар
Серенә төшенгәннәр.

Үзгәрә бара акыл да,
Үзгәрә заманалар;
Заманга чадамый, хәтта
Ава таш баганалар.

Кошлар ничек? Аларның да
Гомер заманча ага.
Һәр ел бүдәнә симерә...
Ә тартай?
Тартай теленнән таба.

АЛАША

Нигә кинәт искә төште әле
Җиккән атым — көрән алаша?
Аның белән тәүге бураздамны
Мин сызганмын икән ләбаса!..

Чит өердән ул адашып килеп
Кушылгангамы тай чагында,
Колхоз халкы аны «апалнай» дип
Йөретте гел безнең авылда.

Әй мәхлугың!.. Юаш иде... Унган...
Куплар хәйран калды көченә.
Тик бернинди камыт ярамады,
Камыт тиде һәрчак үзенә.

Купме сөрдек!.. Үсмер чакларда да
Күңел икән бик тиз ертыла...
Бураздадан чыкса, ачуланып:
«Буразна!» — дип салдым сыртына.

Хәзер инде гафу үтенергә
Мин мең тапкыр әзер атымнан.
Атлар да шул, бөек шагыйрьләрдәй,
Кыска гомерлеләр затыннан.

Ә мин һаман сабан сөрәм төсле,
Көч тә, тир дә байтак түгелгән.
Тик сабаны минем кулда түгел,
Сабанга — мин, ул мин җигелгән!

Сабан тарту — сабан тоту түгел,
Яныл-пешеп тарткан сурәттә.
Буразнадан чыксам: «Буразна!» — дип
Тондырдылар минем йөрәккә.
...Кирәккәдер, бәлки, кирәккә.

ЯКТЫ КҮЗДӘ

Адәм баласының гомер буе
Кырыкмаса-кырык эше бар.
Ә кыр эшен элек якты күздә
Тәмамлаучан булган кешеләр.

Гомерем дә гүя иген кыры —
Күпме сөрдем, чәчтем, тырматтым,
Төрле елда төрле уңыш урдым,
Төрлеләрен куйдым зуратның.

Бар кылганны якты күздә кылдым
(Яман эшләр генә яшерен).
Якты күздә кешеләргә ачтым
Йөрәгемнең якты һәр серен.

Гомерем бер учма кебек кенә,
Елларымны әгәр учласам.
Бәхеттер ул — гомер кибәнен дә
Якты күздә әгәр очласаң...

ӘТИЕМӘ

Быел синнән мин егерме яшькә —
Төгәл егерме яшь! — өлкәнмен.
Ике яшьтә ятим калган сабый
Кайсылай озын гомер иткәнмен.

Ләкин еллар, гүя, ялкын булып,
Ялкын булып барын ялмаган:
Синнән, әткәй, хәтта бер комарткы,
Хәтта төсең җирдә калмаган.

Шул тикле үк, җиргә сеңгән кебек,
Мөмкинмени эзсез югалу?
Дөнья көткәнсең бит! Бар тормышың
Булмагандыр бушка юану?

Син зимагур түгел — сөргән җирең,
Җиккән атың булган, үз йортың.
Көн-төн эштә... Хәтерләткәнсеңдер
Кырмысканы яки бал кортын.

Мирас итеп нәрсә калдырдың соң?
Бар мөлкәтең калган — бар дөньяң!..
Сөргән җирең калган, агач йортың,
Агач сукаң, тырмаң, ат-арбаң...

Әмма еллар, гүя, ялкын булып,
Ялкын булып барын ялмаган...
Бер карасаң, синнән миңа, әткәй,
Мирас булып берни калмаган.

Калган! Нигез калды! Аны, әткәй,
Сатып ашамадык... Сатмадык!
Өч малаең — өч яугирең яуда
Нигезне һәм илне сакладык.

Бөтенләй үк сүнеп юк булырга
Очкын түгел җаны кешенең...
Мин — Нәҗметдин улы: димәк, әткәй,
Калган миндә синең исемең.

Миңа күптән Нажар Нәҗми диләр...
Нәҗми исә йолдыз дигән сүз.
Исемемә ләкин җисеме шул
Туры килгәннәрдән түгел без.

Йолдыз булу — балкып янудыр ул...
Балкымадым — яндым нибары,
Үз-үзеңнән ерак кителмәде...
Балкыганнар — биек, югары.

Ә барыбер читкә тибелмәдем,
Кимсетмәде мине җир-әсәм *.
Миңа карап өрсә өрде бары
Төрле көчек, төрле хөрәсән.

Үз юлымнан барам әле —
Сүнгәнче мин янам әле.

БУ ҖИРЛӘРДӘ...

Рәми Гариповка

Туган телдә, үз телендә генә
Аңлашалар кебек бу җирләр.
Аңлашкандай туган телләрендә
Новгородлар, Псков, Суздальләр.

Тау да тау һәм тау да урман монда,
Ә тауларга юлдаш һәр үзән.
Бөтенесен дә ярларына тезеп,
Боргаланып ага Юрүзән.

Табигать бер бөек шагыйрь кебек,
Һәр тауны һәм кырны, игенне,
Кафияләп, шигырь юлларына
Шундый оста салган шикелле.

---

* *Җир-әсәм* — башкортча: җир-анам.

Илаһи бер бөтенлек бар монда —
Берни артык, берни ким түгел,
Матурлыкта уйчанлык бар монда,
Ямьлелекләр коры ямь түгел.
Тәнгә, җанга үтәр сихере бар,
Шигыре бар, моңы, теле бар.
Башка телдә аңлап бетермәслек
Тарихы бар, рухи түле бар.

Үз телендә һәм үз лөгатендә
Аңлашалар кебек бу җирләр,
Аңлашкандай туган телләрендә
Новгородлар, Псков, Суздальләр.

ШАДРА ПӘРИ

Бала чакта дуслашып та,
Үстек исем аташып та:
Кемдер «Шар күз», кемдер «Борча»,
Кемдер «Күркә», ә мин исә —
«Шадра пәри»... «Шадра пәри»...

Балалыктан һәр сүз сеңеп
Кала икән күңеленә:
Кайда барма, булды юлдаш
Минем бөтен гомеремә
«Шадра пәри»... «Шадра пәри»...

Үсеп җиттем... Булдым гашыйк —
Ул фәрештә иде, шөйлә.
Карашлары әйтте кебек:
«Син тиң түгел, түгел миңа,
Шадра пәри... Шадра пәри...

Гомер үтте... Хыялымның
Очтым сыңар канатында,
Ничек булсам, калдым шулай
Мин матурлык арасында —
Шадра пәри... Шадра пәри...

Матурлыкның чиге юктыр,
Аның чиген таймадым мин.
Кеше матур булсын өчен,
Матурлыкны җырладым мин —
Шадра пәри... Шадра пәри...

НИШЛӘР ИДЕҢ?

(Туган авылыма тагын бер сүз)

Даны чыккан авыл, калаларны
Күреп беләм, беләм ишетеп.
Әгәр синдә Пушкин туган булса,
Нишләр идең микән, Миңешне?

Нишләр идең? Изге булыр иде
Даһи аяк баскан урыннар —
Минем сөргән, урак урган кырлар,
Җәен печән чапкан болыннар.

Пушкин туган көнне һәр ел саен
Шаулап бәйрәм иткән мәлләрдә
Сиңа күпме кунак килер иде
Бөтен җирдән, бөтен илләрдән!

Татлылардан-татлы тоелыр иде
Җир җиләгең, каен җиләгең,
Ямьлеләрдән-ямьле күренер иде
Тау буйларың, Мишәр төбәгең.

Соклануның чиген белмәс иде
Шагыйрь үзе белән йөргәннәр,
Агыйделгә хәйран калыр иде
Үрбашына менеп күргәннәр.

Үрбашыннан чикләвеклек аша
Үрчокырга төшкән сукмаклар
Алып килер иде Акчишмәгә —
Суын эчәр иде кунаклар.

Зәмзәм чишмәсе дип аны һәркем
Атар иде — гади инешне.
Тора-бара «Шигырь Мәккәсе»нә
Син әйләнер идең, Миңеште!

Синең алда тоныкланыр иде
(Әгәр җырның булса ертыгы)
Бөек Кырлай, шүрәлеле урман,
Җилем-Каран, бөек Сыркыды.

О син, хыял! Әй, мин — ярты акыл!
Нигезсез соң хыял буламы?!
Манарадан азан әйткән җирдә
Пушкин тикле Пушкин туамы?!

Ә һәр халык үз Пушкинын биргән,
Газап чигеп, кан һәм тир түгеп.
Үз даһиен биралмаган халык —
Кысыр чәчкә аткан гөл кебек.

Тик даһилар буш урыннан килми,
Алар — улы бөек халыкның,
Үз иркенә һәм үз язмышына
Үзе хуҗа булган халыкның.

Күпме кеше синдә туган, үлгән...
Синекемен мин дә — уңмаган.
Син үзеңчә, шулай калдың,
Ярый синдә Пушкин тумаган...

АҢЛАМАССЫҢ БУ ДӨНЬЯНЫ

Әйе, типтереп яшәлде...
Язу-сызу — шул булды эш.
Ял белмәдем: көн — эш, төн — эш,
Булды елау, булды көлеш.

Бер йөкләмә алынмады,
Беркем белән ярышмадым,
Үзем беркемне узмадым,
Узганнардан калышмадым.

Мактадым... Тик макталмадым
Ярышларда узган өчен;
Яраттылар кебек мине
Йөрәккә юл сузган өчен.

Язганымны да күп вакыт
Мактый-мактый хурладылар.
Аңламассың бу дөньяны —
Хурлый-хурлый зурладылар.

Бар мактау да тигез түгел —
Җыр да тигез җырланмады.
Зурлаучылар хур булмады.
Хурлаучылар зурланмады —
Аңламассың бу дөньяны.

ТАТАР ТЕЛЕ

Вы, прадеды наши в недоле
мукою запудривших лик,
на мельнице русской смололи
заезжий татарский язык.

Ярослав Смеляков

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең —
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

ПАРИЖ ӨСТЕНДӘ

Казан дәүләт университеты профессоры Миркасыйм Госмановка

Без Эйфельдә... Уч төбендә кебек
Бөтен Париж — Җир һәм Ил даны.
Әнә Бастилия... Монмартр... Конкорд...
Ә якында Марс яланы.
Париж — тарих... Күпме күкрәү үткән,
Күпме исем монда яшьнәгән.
(Парижны да күрми торып, димен,
Моңа кадәр ничек яшәлгән?)
Без биектә... Без — башкорт һәм татар,
Без зур милләт Париж өчен дә.
Сөйлә әле,— диден,— «Татар телен»,
Яңгырасын Париж өстендә.
Без татар һәм башкорт — кан кардәшләр,
Миндә исә тибә ике кан:

Үзем башкорт, әмма татар теле —
Анам теле миңа тумыштан.
Язык түгел беркем алдында бу,
Туры килгәч язмыш язмышка.
Ә язмышлар «тел, лөгать вә... әхлак»
Бер тамырдан, бер үк сулышта.
Без әле дә бер үк сулыштабыз
Чит бер илдә — француз җирендә,
Ярсып-ярсып шигырь укышабыз
Я башкорт, я татар телендә.
Аста Париж... Син уйларың белән
Алып киттең мине Казанга.
Париж түбәсеннән киттең алып,
Бүгенгедән үткән заманга.
Кайдан карарга соң зур Казанның
Ак бүгенен, кара үткәнен —
Сөембикә манарасынннанмы,
Манарасыннанмы әллә
Баумандагы кызыл чиркәүнең?
Юк, карыйк яңа биеклектән —
Син укыткан биек бинадан.
О, университет! Альма-матер,
Күпләр мәшһүр аңа бинаән!
Күз алдында менә
Сөембикә,
Тукай, Җәлил, Ирек мәйданы,
Әнә Болак, Идел, Яңа бистә,
Арча кыры, Печән базары...
Казанда да күпме күкрәү үткән,
Күпме исем балкып яшьнәгән!
Бер уйласаң, Парижны да күрми,
Яшәп булган... ә бит яшәлгән!
Без Эйфельдә — аста кайный Париж —
Исемендә дөнья тарихы.
Бу мәл Казан ничек кайный икән?..
Казан, Казан — татар Парижы!..

БАР!

Гасырлардан, иске заманнардан
Тутыкмаган иске хәбәр бар.
Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер:
«Татар барда,— диеп,— хәтәр бар».
Кайда гына хәтәр юк икән соң?
Ул бар, булган һәм ул булачак.
Хәтәрсезме булды безнең заман,
Безнең яшьлек, безнең бала чак?
Безгә генә килгән кебек иде
Дөньяның бар хәтәр көннәре.
Яуда гына күпме ятып калды
Татарның да кеме, кемнәре?!
Хәтәр барда да бит татар бар ул:
Барган икән унау үлемгә,
Аның берсе — бер билгесез Әхмәт,—
Туры килүме бу? Кем белгән...
Бер кабердә өчәү ята икән,
Аның берсе — татар егете.
Туры килүме бу? Әллә бары
Горурлануыммы үз итеп?..
Хәтәр барда руслар белән бергә
Без барыбыз булдык кулга-кул.
Терелмәй ут эчләрендә янды
Сабакташым, башкорт Үтәгол.
Бергә булдык казакъ яки грузин,
Үзбәк, якут яки әрмән дус.
Төрле булдык. Бөтен биеклекләр
Казбек түгел, яки — Эльбрус.
Татарга да Эльбрус биеклеген
Дәгъва итүләр дә ят монда.
Һәрбер халык тик үзенчә бөек,
Ә җырым бит татар хакында.
Кайда бакма — хәтәр җирдә татар,
Адәм ышанмаслык даны бар.

Карбышевтан кем сораган? Ә ул:
«Миндә,— дигән,— татар каны бар».
Кая бакма — хәтәр җирдә татар,
Үлемнәрнең сыртын сындырып,
Утлардан да, Моабитлардан да
Кем соң чыкты моңлы җыр булып?
Палач балтасына башны тотып,
Көлеп үлгән икән татарлар,
Дошман өчен, сатлык җаннар өчен
Татар барда, чынлап, хәтәр бар...
Бар!

КАЗАННЫҢ ТАТАР ЗИРАТЫНДА

Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы.

Г. Тукай

Шушы сүзләрне укыдым
Мин кабер ташларыннан,
Алар уелган шикелле
Әче күз яшьләреннән.

Шагыйрь һәм кеше күңеле
Эреп коелган бергә.
Шагыйрь сүзләрен ябынып
Яталар төсле гүргә.

Әй язмыш, шагыйрь язмышы
Кешеләр бәгырендә!
Сүзләр көчсез — бер сүз дә юк
Шагыйрьнең каберендә.

Тик анда тере чәчәкләр,
Ташында көн яктысы.
«Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы».

ТАТАР БУГАЗЫ

Габдулла Байбуринга

Но я
себя
смирял,
становясь
на горло
собственной песни.

В. Маяковский

Башкорт, татар — телләр тәрҗемәсез...
Башкортча бар җырым, моң-сазым.
Татар, башкорт кайда гына юк соң?
Әле менә Татар бугазын
Ярып киләм... Теплоходта киләм.
Бер горурлык тоям күңелдә.
Помкапитан якташ: «Саумысез»,— дип
Сәлам бирә татар телендә.
Бер горурлык тойдым — Сахалинда
Башкорт кызы,— таныш кыз миңа,—
Балаларга рус теле укыта
Кинйәбулатова Тәнзилә.
Бугаз дисәң... Җир йөзендә сансыз...
Зуры, бәләкәе... башкасы.
Кайда, дисәң, Татар бугазында
Көнчыгышның Диңгез капкасы.
Сахалиннан материкка Татар
Бугазын мин ярып киләмен.
Палубага түгел,
гүя үз җырымның
Бугазына басып киләмен.
Әй басылсын! Хәтта бөеклекнең
Кала Җирдә бары беразы.
Үзгәрешле дөнья! Синдә әле, димен,
Озак яшәр Татар бугазы.

ЯНГАН ЙОРТ

Сугыш утларында күпме
Кала, давыллар янды.
Туган-үскән өйдән күпме
Көл-күмер торып калды.
Безнең якта дошман уты
Өйләрне яндырмады.
Әмма бер генә өйне дә
Хәсрәтсез калдырмады.
Өй рәтеннән күпме ятим,
Күпме тол хатын калды.
Күпме йөрәк, күпме язмыш
Кайгы утында янды.
Йорт янса, аны яңадан
Матурлап, салып була.
Әй, ятимлек... Ул — янган йорт,
Гел янган көе тора.

ЯЛГЫЗЛЫК

Китәсем килә, ә кайтасым килми,
Җиңел түгел ул юл йөрүе.
Әмма авыр ялгызлыктан китеп,
Ялгызлыкка кайтып керүе.
Бер үк караш, бер үк сүз агышы,
Бер үк шатлык, кайгы бер төрле.
(Моны язган чакта тышта берәү
«Дөрес!» дигән кебек төчкерде.)
Бер төрле уй, бер төрле җан һәм хис,
Бер үк төрле хаклык, хаксызлык.
Бер төрлелек... Күңел җиләгәндә
Шулдыр, ахыры, үзе ялгызлык.

* * *

Бәхеткә дә, рәхәткә дә микән,
Әллә кеше бик тиз күнегә —
Таудай шатлык беленми дә кебек,
Бер түмгәктәй кайгым — күренә.

Тау янында берни түгел түмгәк,
Ул күзгә дә сирәк чагыла.
Ләкин кеше биек тауга түгел,
Түмгәккә шул килеп абына.

* * *

Барысы да соңлап килде миңа:
Язмыш йөреде гелән шаяртып,—
Соңлап килде яшьлек, килде шигырь,
Яшьлегемдәй чәчен агартып.

Әллә кайдан үтте сөю юлым,
Ул хыялый, борма юл иде.
Җан тетрәтеп килде чын мәхәббәт —
Килде, ләкин инде соң иде.

Артык соңлап аңлый башладым мин
Яшәү серен, тормыш юлларын.
Кайда барма — һәрчак ашыктым мин,
Ләкин үзем һәрчак соңладым.

Ирештем дә кебек морадыма,
Хәзер миңа башка ни кирәк?
Тик барысы соңлап килде миңа,
Мин туганмын, ахыры, иртәрәк.

АК КАЕННАР

Ак каеннар, Урал каеннары,
Бу җирләргә кайдан килдегез?
Туган Уралымның киртләч-киртләч
Ташларына ничек мендегез?

Юк! Сез адәм балалары түгел —
Бер килергә, я бер китәргә.
Җир һәм кояш менә шушы җирдән
Урын биргән сезгә үсәргә.

Шушы җирдә туган ата-бабам,
Шушы җирдә туып үскәнмен.
Ак каеннар, сезнең белән бергә
Агыйделнең суын эчкәнмен.

А, шуннан да бармы зур якынлык:
Без туганнар җир һәм су аша.
Безнең туганлыкның тамырлары
Шул җир-суда килеп тоташа.

Ак каеннар, нинди милләттән сез?
(Мондый сорау, ахры, алйотча.)
Сез башкортча яфрак ярасыз бит,
Җырлыйсыз да кебек башкортча.

Ак күлмәген киеп тауга чыккан
Кызлар шикелле сез, каеннар!
Зифа башкорт сылулары дип тә
Атарга бит минем хакым бар.

Атамыймын...
Уралда гына бит үсмисез —
Күрдем сезне Казан артында,
Чуваш, бурят, коми җирләрендә.
Күрдем сезне Мәскәү ягында.

Хәтердә әле Польша яланнары,
Утлар аша юллар үткәнем.
Ак каеннар, сезнең күләгәдә
Булды, арып, яллар иткәнем.

Карелиянең зәңгәр күзләре, дип
Йөретәләр зәңгәр күлләрен.
Күлләрен һәм шул ук каеннарын
Күргәнем бар минем, күргәнем.

Сез бер төрле милләттән дә түгел,
Һәр халыкның сез җир туганы.
Чикләнүдән яки чик белмәүдән
Сез югары, сез бик югары.

Сез горур һәм сез киң күңелле —
Бөеклек тә шунда түгелме?

ГАҖӘПЛӘНДЕЛӘР

Бер караеп, бер ялтырап,
Ни эшләсәм — гел аптырап,
Гаҗәпләнделәр;

Йөгерешләрдә узып килсәм,
Сабагымны яхшы белсәм,
Гаҗәпләнделәр;

Янымда бер сылу торса,
Бер сылу кыз гашыйк булса,
Гаҗәпләнделәр;

Берәр җирдә бүләк алсам,
Берәр юньле шигырь язсам,
Гаҗәпләнделәр;

Җаваплы эшкә куйсалар,
Я бер җиргә сайласалар,
Гаҗәпләнделәр;

Фикерле бер телмәр тотсам,
Берәр юньле әйбер отсам,
Гаҗәпләнделәр;

Күп нәрсәгә өйрәнгәнгә,
Хәтта минем өйләнгәнгә
Гаҗәпләнделәр;

Бер караеп, бер ялтырап,
Ни эшләмә — гел аптырап,
Гаҗәпләнделәр;

Менә бүген,— ах, саксызлык! —
Эшләдем бер акылсызлык —
Гаҗәпләнмәделәр...

*АННА АХМАТОВАГА**

Бу дөньяда үзеңнеке үз шул...
Ә бит сезне тугач, иң тәүдә,
Беләм, Анна Андреевна, беләм,
Чукындырганнар чиркәүдә.
Безгә исә мулла исем кушкан,—
Сәдакасын алып, рәхмәтен,—
Нәҗметдинен, Сәйфетдинен кушкан,
Мөхәммәтен яки Әхмәтен...
Ә шул мулла кушкан исемнәрдән,—
Яратыпмы әллә, нигәдер,—

* *Ахматова* — псевдоним. Шагыйрьнең чын фамилиясе Горенко.

Фамилиягез итеп алгансыз сез
Шуларның бер Әхмәт дигәнен.
Заманнарның каһәр чагында да,
Кимсеткәндә кеше кешене,
Теләгәнчә түбәнсеткән чакта,
Кайберәүләр безнең ишене,
Тәкәбберләр санга сукмаганда
Исем белән хәтта җисемне,
Сез бит, Анна Андреевна, горур
Йөреттегез шушы исемне.
Йөреттегез гомерегез буе
Шагыйрь булып, кеше булып та.
(Шагыйрьлекне, кеше кешелеген
Күреп була күзне йомып та.)
Ә бит булды сезгә өрүчеләр
Уяу көе, ачык күз белән.
Кичерегез, хәтта мин дә бер чак
Өрдем, көчек, ихлас күңелдән.
Өрү белән йолдыз сүнәмени?!
(Барысына, ахры, күндегез...)
Сез үзегез булып яндыгыз да
Һәм үзегез булып сүндегез.
Укытканнар сезгә җеназаны
Сез кушканча, диләр, чиркәүдә.
Кайсыберәү, зур вакыйга итеп,
Салды шуны шигъри үлчәүгә.
Шундамыни сезнең сезлегегез,
Югары бит сезнең инану.
Сезнең алда тигез булгандыр, дим,
Бу дөньяның Әхмәт, Иваны.
Сез өстенсез төрле ваклыклардан,
Ә бит йолдыз янмый түбәндә.
Мин бер якты югарылык күрәм —
Сезне күрәм, шагыйрь дигәндә.

* * *

Каләм алсам, төшеп китә кулларымнан,
Утырып елыйм, язармын дип моңнарымнан.
Юлга чыксам, һәркем миңа юл өйрәтә —
Шуңа, ахры, язармындыр юлларымнан.

ШИГЫРЬ

Вазифалар, дәрәҗәләр белән
Чуарланып беткән дөньяда
Синең генә, шигырь, дәрәҗәң юк,
Зур вазифаң мәгәр булса да.

Дәрәҗәләр... Сиңа кирәкме соң?
Сиңа берни юк бит өстәсе.
Син бит үзең әллә кайчан алла,
Юк бит сине алла итәсе.

Бөтенесе синең алда тигез:
Кем ул, кайда, нишли, кай җирдән?
Патшаларның да бит акыллысы
Сине сөйгән, сиңа баш игән.
Сөймәсә дә, барыбер баш игән.

Югарыдан баккан кайберәүгә
Кирәгең дә юктыр, кем белә,
Ләкин син бит йөрәк өчен кирәк,
Син барыбер түгел кешегә.

Һәм барыбер түгел синең өчен
Бу дөньяның дусы, дошманы.
Дөньяны бит акыл, йөрәк тота,
Дәрәҗәләр тотмый дөньяны.

МӘХӘББӘТНЕҢ КИЛГӘНЕН МИН ТОЯМ...

Сибгат Хәкимгә

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Якыная төсле миңа ул.
Төрле усал, яман карашларны
Өтеп, этеп, җырлап килә ул.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Узган язмышларга үч итеп,
Килә кебек, якыная кебек:
«Иң бәхетле итәм үзем»,— дип.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Тоям аның авыр булырын.
Аткарылмаганнар аткарылыр —
Я, ниһаять, табар урынын.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Ләкин аңа калмам кол булып.
Тормышымның очсыз хыяллары
Очачаклар күккә көл булып.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Чигенә кебек артка яшь саны.
Яшьлегемнән кабат килә-килә,
Яшәртермен кебек дөньяны.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Үзе килә, килә тирәннән.
Башкодасыз, димләүләрсез килә,
Өстән түгел, килә түбәннән.

Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям —
Язмыш бүләк иткән уттыр ул...
Аһ, җиреңнең җирле мәхәббәте!
Шуннан да зур бүләк юктыр ул...
Мәхәббәтнең килерен мин тоям...

ӘДӘПСЕЗЛЕК

Үз уемнан үзем дертләп киттем
Итәгендә мәшһүр Машукның —
Лермонтовның ике гомерен бит
Яшәгәнмен... Мин дә мут-шукмын!..

Ике гомер... Нигә әле ике?!
Улмы минем ап-ак, ак кына?!
Миңа да бит Варшау янында да,
Берлинда да төзәп аттылар.

Ике гомер... Нигә әле ике?!
Пулялардан посып калдыммы?
Я булмаса, дошманымнан куркып,
Яшеренеп артта бардыммы?

Ике гомер... Нигә әле ике?!
Улмы булды минем шоп-шома?!
Үземе соң, ачып ишегемне,
Керде бәхет минем йортыма?

Миңа да бит шагыйрьлекне аз-маз
Биргән төсле ходай тәгалә.
Ике гомер... Нигә әле ике?!
Шул икедә нинди мәганә?

ИКЕ ТАШ

Наталья Пушкинага

Күңелемдә әллә нинди тойгы —
Көнләүме ул, әллә үпкәме?
Айда түгел, гасыр исәбендә
Язмышларның уйнап уткәне.

Ул «уеннар» күптән тукталганнар,
Туктасы юк, кабат туктасы.
Зыяратта ике кап-кара таш —
Гомерләрнең салкын ноктасы.

Наталья, мәшһүр, о, Натали,
Кара ташның берсе сез бит! Сез!
Пушкин башка җирдә... Ә сез монда
Бер генерал * белән икегез.

Күңелемдә әллә нинди тойгы...
Көнләүме ул әллә үпкәме?
Сез Пушкина булып балкыдыгыз,
Сез Пушкина! Юк бит бүтәне!

Башка белән сезне күз алдына
Китерүе, о, соң мөмкинме?..
Җырга кардәш булыр өчен генә
Яратылгансыздыр шикелле.

Гасыр аша мин дә гашыйк сезгә —
Хыялда соң нинди язык бар?!
Чибәр хатыннарга һәр гасырның
Ирләре бертөрле гашыйклар.

---

* Генерал Ланский — Н. Н. Пушкинаның икенче ире.

Миндә дә бар бераз шәрык каны,
Ул да инде хәзер басылган.
Җаным дулый, көнләшүдәнме ул,
Үпкәдәнме, әллә ачудан...

Язмышларга кысылышларым юк,
Берничек тә мин бит хак түгел.
Ташларыгыз да пар... Ник, ичмасам,
Берсе кара, берсе ак түгел!?

Күңелемдә әллә нинди тойгы...
Азгамы ул әллә күпкәме?..
Айда түгел, гасыр исәбендә —
Язмышларның уйнап үткәне.

КИЧЕР МИНЕ

Муса Җәлилгә

Демблин, Радом, Берлин... Шул юллардан
Алып барды сугыш мине дә.
Шул юллардан дошман, чигенә-чигенә,
Алып киткән икән сине дә.

Бер үк юлда ике төрле язмыш...
Ә мин шунда исән калганмын.
Әйтерсең лә дошманнарны куып,
Мин тик сине эзләп барганмын.

Хәтерлимен төрмә коймаларын,
Бәреп кергән тимер капканы.
Үз күзләрем белән күргәнмен мин,
Үз кулларым белән тотканмын мин
Сине харап иткән балтаны.

Бу хәтерләү нигә кирәк хәзер —
Синең даның шуңа калганмы?!
Палачларга сине бирмәс идем,
Кичер мине — соңлап барганмын!

БУЛГАНДЫР БИТ...

Габдулла Тукайга

Булганнар бит бөек шагыйрьләр —
Тугач, урын — алтын бишектә.
Үскәч — киткән, кайткан чакларда,
Кеше торган саклап ишектә.

Булган тагы бөек шагыйрьләр,
Тар бүлмәдә череп сүнгәннәр.
Бала чакта исә базарда:
«Асрарга бала бирәм! — дип,—
Кем ала?!» — дип сатып йөргәннәр.

Әй, язмышның шомлы агышы,
Бөеклекнең алтын ярлары...
Гомерендә — халкы язмышы,
Җырларында — халкы моңнары.

Хәзер инде башка заманнар,
Заманнарда башка базарлар,
Базарларда — башка малайлар,
Малайлар да — башка Нажарлар.

Күңелемнең заман кошчыгы! —
Басып сайрый алтын киртәгә.
Сатылырга бүген әзермен,
Тукай чыкса миннән иртәгә.

«Я кем ала?!» Сезгә кирәксәм,
Мин тукталам табып мәрхәлә *.
Аһ, алай да килми кешегә
Шагыйрь дигән бөек мәртәбә.

ЧИТ ТЕЛ АША...

Рәсүл Гамзатовка

Онытмыймын, берчак шулай, белгәч,
Мин Мостайдан өлкән икәнне,
Синең миңа: «Нигә болай булгач,
Син билгеле түгел?» — дигәнне.
Өйрәнелгән синең тапкырлыкка,
Сүзләреңнән озак көлештек.
Көлештек тә, шәрабыңны эчкәч,
Без үбештек бугай, үбештек!

Дустыңның мин дусты булган өчен
Дус күрәсең бугай бүген дә.
Ул турыда синең шигырь дә бар —
Сөйләдең син авар телендә.

Яшермимен, синең кебек данлы
Кеше белән, ничек булса да,
Дус булуы ул горурлык, димен,
Яшәү җиңелрәк дөньяда.

Тик авырдыр сезнең кебекләргә,
Бигрәк тә синең кебеккә.
Чит тел аша күпме «...шагыйрьләрнең
Баш өстеннән» сикереп биеккә

---

* *Мәрхәлә* — юлчылар туктап китә торган урын.

Очар өчен кирәктер ул булу
Үз халкының Пушкин, Тукае.
Ә соң Тукай, Мәхмүт бөтен илгә
Синдәй билгелеме, дускаем?

Һәр юлында очкын чәчрәп тора,
Ут булмый бит, булмый һич юктан.
Анда чыңлау!.. Чыңлап торганны бит
Ясап булмый кызыл балчыктан.

(Балчыктан ул чүлмәк ясап була,
Чүлмәкнең дә була үз чыңы.
Кайсы чакта чүлмәк тавышында
Күмелеп кала чыңның иң чыны.)

Һәр талантның җирдә үз урыны бар,
Һәр телдә бар акыл, моң вә чәм.
«Син Тукайдан өстен!» — дияр идем,
Татар телен әгәр белмәсәм.

БЕРЕНЧЕСЕ

Шәехзадә Бабичка

Дүртөйледән без дүртәүбез * —
Аннан башлап, миндә бетә.
Дүртнең дәвамын якташлар
Аның кебекләрдән көтә.
Күпме еллар инде киткәненә,
Безнең гомер еллар санында.
Алтын орлык арасында тавык
Тибенгәндәй, үлек җанында

---

* Шәехзадә Бабич, Бәдрүш Мокамай, Зыя Мансур һәм шушы юлларның авторы.

Тибенәбез һаман, чокынабыз...
Үлгәч тә бит түгел ул тыныч.
Үлгәннәрдән дәме без куркабыз,
Гомереме әллә куркыныч?..
Мондый язмыш кемгә тәтегән соң —
Балкып сүнүе дә үзенчә.
Күпме кешеләрнең язмышына
Керде хәтта үле көенчә.
Нигә шулай? Әллә аның рухы
Артык усал, артык яманмы?
Әллә заман аны аңламыймы,
Улмы аңламады заманны?
Их, барсы да аңлашылып торса,
Ул да булмас иде үзенчә.
Мин дә язмас идем бу шигырьне,
Аннан өлкән малай көемчә.
Дүртөйледән без дүртәүбез —
Аннан башлап, миндә бетә.
Дүртнең дәвамын якташлар
Аның кебекләрдән көтә.

ХӘТЕРЛӘҮ

Гамир Насрыйга

Кая барма — үткән искә төшә,
Ә үткәннәр ерак калалар.
Шулай инде — гомер узган саен,
Хәтерләүләр арта баралар.

Артсын әйдә... Ләкин алда хыял,
Күпме өмет барыр юл сала.
Алда — хыял... Артта — хәтерләүләр...
Кеше яши шушы уртада.

Ирексездән сине хәтерлим мин,
Караш салам диңгез иңенә.
Ул кемнәрне генә кочмаган соң,
Тик оныткан сине, мине дә.

Без утырган ташны дулкын кага,
Таш бирешми дулкын какса да.
Ташлар озак яши, я шомарып,
Я мүкләнеп-нитеп булса да.

Мәңгелеккә килмәгәнмен мин дә,
Вакыт үтә — булмый баш булып;
Ташлар озак яши... Ярый әле,
Яратылмаганбыз таш булып.

АЛАР ӨЧӘҮ ИДЕ

Алар өчәү иде: Хәсән Туфан,
Сибгат Хәким, Кайсын Кулиев.
Күз алдымда Туфан карашлары,
Сибгат йөзе, Кайсын көлүе.

Алар өчәү иде... Ә өчесе бер җан —
Җан-агайлар миңа, җан-дуслар.
Өчесе дә кеше йөрәгендә
Нур балкыткан алтын йолдызлар.

Алар өчәү иде... Өчесе дә
Гомеремә булды өч терәк.
Күңелемә — күңел, җырыма — җыр,
Йөрәгемә моңлы бер йөрәк.

Исән чакларында мин аларның
Барып күрдем туган җирләрен.
Вафат булгач, туган җирләренә
Һәрбересен барып җирләдем.

Әмма алар тереләрдән тере —
Үлем юк ул, юк бит җырларга.
Ә мин үлгәч, алар өчесе дә
Килер кебек мине җирләргә.
Үлем юк ул, юк бит җырларга!

* * *

Михаил Львовка

Татарлардан руска әйләнгәннәр,—
Гасырларга керсәң,— күп инде.
Бөек Ител бөек Волга булып
Безнең көндә аккан шикелле.

Тарих өчен кечкенә бер мизгел
Бер кешенең гомере, базары.
Күз алдында рус шагыйре булды
Насибашның * гади татары.

Рус шагыйре... Хәтта руска авыр
Шундый булу, шуңа ирешү.
Ул кылганны кемдер Россиядә
Кыла алыр микән киресен?

---

* *Насибаш* — Башкортстан АССРның Салават районындагы шагыйрь туган авыл.

ТУГАН ШИГЪРИЯТКӘ

Поэзия! Синнән качар идем...
(Бу уй яман, ят бер чир кебек!)
Качар идем өзелеп сөйгәненнән
Җаны бизеп качкан ир кебек.

Мондый ирләр, беләм, макталмыйлар,
Җан бизүнең нинди хаҗәте?!
Поэзия! Син — тормышым минем,
Син язмышым, шатлык, хәсрәтем.

Поэзия! Ихлас җаннар иле,
Азат фикер, намус, дан иле —
Пушкиннар һәм Лермонтовлар иле,
Тукай кебек изге җан иле.
Илаһилык бар иткән бит сине!..

Булды микән синдә берәр чак
Титул өчен хәтта җанын саткан,
Теләнеп дан, кем даулап яткан
Булды микән синдә берәр чак?

Булдымы соң синдә берәр вакыт
Санга сукмау ходай биргәнне,
Ана сөтеннән, дип сөрән салу
Кәҗә сөте белән кергәнне?

Поэзия! Синнән качар идем...
Үз өемнән качкан шикелле.
Ана булгым килә, дигән хатын
Үз иреннән качкан шикелле.

Ләкин кайда? Кайсы тарафларга
Мөмкин хәзер миңа юл алу?
Үз-үзеңнән качу мөмкинме соң?
Мөмкинме соң китү, югалу?!

ЯУ КЫРЛАРЫ

Яхшылыкмы, яманлыкмы икән
(Мөмкинме ул, әллә түгелме?) —
Үлемнәргә мин күнегәм кебек,
Яу кырында күнгән шикелле.

Күнегәмме? Юктыр!.. Яшәүгә бу
Уяу карау гына, ахыры.
Бер уйласаң, тормыш үзе дә бит
Бертуктаусыз барган яу кыры.

ИРТӘ ТӨШКӘН КАР

Чәчәк иде минем өй алдым...
Иртән торсам — ап-ак җир өсте:
Быел шулай иртә кар төште...
Ә кар кунган кызыл чәчәкләр
Карга тамып калган кан төсле.
Чәчәк һәм кан... Килде хәтергә
Сугыш кыры, чәчәк вакытлар...
Чәчәк гомер үткән окоплар,
Окопларга яуган тәүге кар,
Дошман уты... Күзнең бер таңы,
Тәүге карга аккан дус каны.
Безгә шулай иртә кар төште,
Чәчәкләргә төшкән кар төсле.

ГОМЕРЛЕКТЕР УЛ...

Бар күңелем синдә эри минем —
Мин эримен кебек бөтенләй.
Гомер утә. Аның үтүенә
Күңел бүген бөртек үкенми.

Мин югалам синдә... Киң дөньяның
Тоям хәтта миңа тарлыгын.
Синең белән яшьлегемә кайта
Бөтен җаным, бөтен барлыгым.

Сөю уты — гомерлектер ул,
Сөю сүнсә, гомер юктыр ул.

* * *

Их, ичмасам, еламасаң икән,
Күрмәс идем шундый чагыңны.
Кайгыларың авыр... күтәрә алсам,
Алыр идем бөтен кайгыңны.

Их, ичмасам, еламасаң икән,
Күз яшь сиңа һич хас түгел лә.
Нур идең бит!.. Бөтенесе сүнгән
Бүгенгәме, әллә гомергә...

Их, ичмасам, еламасаң икән —
Тора җаным җаныңа куш булып.
Синдә елый минем мәхәббәтем,
Яшьлек хыялыма кушылып.

БУ ҖИРЛӘРДӘН СИНСЕЗ КИТМИМЕН МИН

Бу җирләрдән синсез китмим, китмим —
Йөрәгемнең шашкан бер мәле.
Шатлыкларга шатлык өстәлсә дә,
Бу дөньяның синсез ни яме?
Бу җирләрдән синсез китмимен мин —
Йөрәгемнең шашкан бер мәле.

Бу җирләрдән синсез китмим, китмим —
Синең беләп күңел тулышкан.
Синең белән, туган җирең белән
Бер тамырдан, без бер сулыштан.
Бу җирләрдән синсез китмимен мин —
Бер тамырдан, без бер сулыштан.

Бу җирләрдән синсез китмим, китмим —
Башка монда һава, су тәме.
Йөрәгеңә, буй-сыныңа күчкән
Җир-суыңның моңы, бар яме.
Бу җирләрдән синсез китмимен мин —
Бу дөньяның синсез ни яме?

* * *

Ачылмаган сер ул — татлы хыял...
Мин хыялга килеп юлыктым.
Ачам, дидем, серне... Ә ачылса,
Серсез калырмын, дип курыктым.

Ачылмаган сер ул — татлы хыял,
Күңелгә бер җәннәт, матурлык.
Сер ачылды... Ә ул ачылса да,
Хыял булып икән калырлык.

* * *

Мине күрсәң, күзләремә багып,
Тотасың да еллар санныйсың,
Күңелеңнең серсез тәрәзәсен
Шундый серле ачып карыйсың.

Әй өметнең алтын канатлары! —
Җилпенергә һаман әзерләр.
Еллар үтә... ә без инде күптән
Еллар кулындагы әсирләр.

КЫЗЛАР ӨЧЕН

Бу бокалны, кызлар, сезнең өчен,
Сезнең саулык өчен күтәрәм.
Шәрапларны коръән хәрам дигән,
Сезнең өчен дәдер ул хәрам.

Шул хәрамны, хәтта хәрәмләшеп,
Эчәм, менә, кызлар, нишлимен.
Мин ике кыз өчен эчәм бүген,
Бөтенегез өчен эчмимен.

Аның берсен үлеп, үлеп сөйдем —
Ул бар дип тә мине белмәде.
Икенчесе гашыйк иде миңа,
Ә мин хәтта якын килмәдем.

Алар белән, бәлки, булыр идем
Бәхетлерәк я иң бәхетсез.
Эчик әле бүген кешеләргә
Булмас өчен каты, бәгырьсез.

БЕРӘҮНЕҢ БЕРӘВЕНӘ

(Шаян җыр)

Исе дә китми тормышның
Туктаусыз гүләвенә,
Үлеп гашыйк була берәү
Берәүнең берәвенә.

Ә ул — берәүнең берәве —
Ходайның биргәненә
Шөкер итми, күз саладыр
Берәүнең берәвенә.

Ә шул берәүнең берәве
Саташа берәү белән,
Ә аңа агыла хисләр
Берәүнең берәвеннән.

Берәүнең берәүләре шул
Берәүгә берәү генә,
Әмма берәү гашыйк була
Берәүнең берәвенә.

Исем китсә дә тормышның
Туктаусыз гүләвенә,
Бүләк булсын иде бу җыр
Берәүнең берәвенә,
Берәүнең берәүләреннән
Берәүнең берәвенә.

* * *

Шатланыр, дип син уйладың бугай...
Туктатып бер урам чатында,
Ләззәтләнеп сөйләп тордың аның
Бик бәхетсез булуы хакында.

Нигә әле миңа сөйләп тордың —
Йөрәк, дидеңме, әллә төнәгән?
Аның мине сөймәгәнен син дә —
Уф!..— беләсең, димәк... сөйләгән!..

Яшермимен, онытырлык түгел
Минем яну, минем көйгәннәр,
Күз яшьләрем аша: «Нигә икән
Мин бәхетсез булдым?!» — дигәннәр.

Әй яшьлекнең ихлас газаплары...
Кем йөрәген алар өтмәгән.
Күрәм, ул бит минем йөрәкне дә
Тетрәтмичә читләп үтмәгән.

Әрнер йөрәк гомер буе әрни,
Бер әрнетеп әгәр китсәләр.
Минем каргыш төшкән, дияр идем,
Каргыш төшү бар ул, дисәләр.

Чынлап та, ул бәхетле түгел...
Ахры, сине хәйран калдырдым:
Шатланыр, дип син уйладың бугай,
Шатланмадым, ә мин — кайгырдым.

ЯФРАК

Утырам ялгыз... Урамда
Көзге җил исә иде.
Ачык тәрәздән бүлмәмә
Бер яфрак очып керде.
Күтәреп кулыма алдым да:
«И син, яфрак,— дидем,—
Җирдә тапталмас өченме
Яныма очып кердең?
Беләм, син миннән югары,
Биектә шаулый идең.
Ә мин яшел, яшь чагыңны
Күреп туя алмый идем.
Әйт хәзер, ни өчен соң,
Саргаеп кипкәч кенә,
Яныма килмәкче булдың,
Өзелеп төшкәч кенә?»

ӨЙЛӘРЕНДӘ УТЛАРЫ БАР

Өйләрендә утлары бар,
Күз алмый торган булам.
Тәрәз төпләренә килеп,
Тамагым кырган булам.

Тәрәзәләре ачык та,
Корылган пәрдәләре.
Кайчак ни көнгә калабыз
Без — алла бәндәләре.

Көндез эштә күрәм дә ул,
Күрүдә хикмәтмени?!
Көндезләр ул — хезмәт өчен,
Мәхәббәт хезмәтмени!

Һәрнәрсәнең үз вакыты —
Шуңа да торган булам.
Тәрәз төпләренә килеп,
Тамагым кырган булам.

Чү! Пәрдә селкенеп куя,
Күңелем шатлык тоя.
Юк! Әнкәсе тәрәзләрен
Шап итеп ябып куя.

Аңламассың ана халкын,
Ул да кыз булгандыр бит.
Аңа да кайчандыр берәү
Тамагын кыргандыр бит.

Җиткән кыз — пешкән җимеш тә,
Тик саклап буламыни?
Һәрнәрсәнең үз вакыты —
Их, саклап буламыни!

Алай булса, мин, сызгырып,
Сүндерәм утыгызны.
Алып китәм үзем белән
Күтәреп йортыгызны.

СИҢА ТАГЫ МИН БЕР КИЛӘМ ӘЛЕ

Утлар сүнде, йолдызлар да сүнде,
Таң нурында йөзә болытлар.
Сүнсә сүнсен утлар, йолдызлар да,
Миндә әле сүнмәс өмет бар.
Сиңа тагы мин бер киләм әле,
Сүнгән йолдызларда эшем юк.
Сине тагы мин бер күрәм әле,
Синнән башка сөяр кешем юк.

Якты дөнья якты түгел төсле,
Ябык төсле ачык капкалар.
Барысы шат, бәхетле дә төсле
Миннән башка, миннән башкалар.
Сиңа тагы мин бер киләм әле,
Бүтәннәрдә минем эшем юк.
Сине тагы мин бер күрәм әле,
Синнән башка сөяр кешем юк.

Йолдызлар да кабат кабындылар,
Кабат янды утлар өйләрдә.
Януларым, көюләрем белән
Алмаштырып төнне көннәргә,
Сиңа тагы мин бер киләм әле,
Утларында минем эшем юк.
Сине тагы мин бер күрәм әле,
Синнән башка сөяр кешем юк.

ЯШЬ БЕР ГАМЬ

Күңелемдә син яшерен бер сер,
Миңа соңлап килгән яшь бер гамь.
Яшерәм мин сине — кешеләрдән,
Ә үземне — синнән яшерәм.

Күңелемдә син яшерен тоткын,
Чыгару юк сине беркайда.
Әй йөрәгем! Үзең шул тоткынның
Бер тоткыны икән, шулай да.

* * *

Үзем сиңа гел үпкәләп барам,
Гүя көйсез мин бер баламын.
Әйтерсең лә күңелем юлларыннан
Гел салулап барган чанамын.

Үпкәләү дә сиңа түгел, ахры,
Бик салулы түгел юллар да.
Үпкәлим шул мине иртә таңнан,
Сине соңлап тапкан елларга.

* * *

Син бәхетсез... Бәлки, киресенчә
Булыр иде, әгәр кавышсак.
Әллә тагын... Безнең тормыш үзе
Аяусыз бер йомак-табышмак.

Нигә кирәк үткәннәрне юрау,
Кичәгегә ялгап бүгенне?!
Минем белән син бәхетсез булсаң,
Мин бәхетле булыр идемме?

КӨЗГЕ КОЯШ

Әй кыздыра кояш, көзге кояш,
Әйтерсең лә чөллә бетмәгән.
Әйтерсең лә көннәр кыскармаган,
Әйтерсең лә җәйләр үтмәгән.

Әй кыздыра кояш, әй елмая...
Ә кайдадыр янәш, якында
Тирәләп бит йөри карлы яңгыр,
Тирәләп бит йөри салкыннар.

...Син әйтәсең: каннар кайнар әле,
Без яшьләрдән, дисең, ким түгел.
Әй елмая кояш... Көзге кояш...
Көз — көз инде, җәйгә тиң түгел.

ӘЛЛӘ НИЛӘР ӘЙТЕР ИДЕМ СИҢА...

Безгә дигән гомер төргәгеннән
Берәм-берәм еллар коела.
Бер җылы сүз әйтәлмәдем кебек,
Әйтәлмәдем еллар буена.

Кайгылардан кемнәр азат икән,
Шатлыклардан кемнәр туйган соң?
Син шуларны уртаклашып җирдә
Яшәр өчен генә тугансың.

Синең белән еллар җиңелрәк,
Бәхет юлдаш минем юлыма.
Әлләниләр әйтер идем сиңа,
Әйтәлмәмдер гомер буена.

МИҢЕШТЕ

Бар булганым синңа охшаган...

Йортың, холкың, табигатең белән
Ямьле як дип син дан алгансың.
Ләкин килгән-киткән кешеләргә
Тискәре як булып калгансың.

Тискәре як... Олы юлдан ерак...
(Ерактагын авыр күрергә.)
Син бернинди юл өстендә түгел,
Сиңа кирәк борылып керергә,
Я булмаса төбәп килергә.

Мин дә Миңештедән! Миңештеле!
Бар булганым — син ул, җир-суым!
Йортым, холкым, табигатем белән
Гаҗәп түгел синдәй булуым.

Мин дә, димәк, шул тискәре яктан —
Бар дөньямны минем күрергә,
Үтеп кенә китү мөмкин түгел,
Кирәк миңа борылып керергә,
Я булмаса төбәп килергә.

ЭЗЛӘМИМ

Үлгәннәрне һаман эзлиләр,
Ә үлгәннәр моны белмиләр...
Эзләмәгән, ахры, кеше юк,
Үлгәннәрнең монда эше юк,
Үлгәннәрне һаман эзлиләр.

Әй, агаем! Тагы шигырьгә
Син керәсең, әйе, керәсең,
Шигырьләрдә яшәр өченгә
Син югалдың яуда, күрәсең.

Син югалдың, әйе, югалдың...
Күпме гомер сине (узган шул!)
Эзләмимен... Әгәр эзләсәм,
Табармын, дип куркам... Куркам шул.

Эзләмәгез, үзе кайтыр, дип
Үлде әнкәй, көтеп ала алмый.
Әнкәй өчен, димәк, син тере,
Үлгәннәрне үлем таба алмый.

Мин дә берчак дөнья куярмын,
Миңа да бит килер мәңге ял...
Эзләмимен сине, агаем,
Син миңа да мәңге тере кал.

ВАСЫЯТЬ

Як умру, то поховайте...

Т. Шевченко

Үлгәч, мине җирләсәгез иде
Миңештәнең сез Үрбашына.
Кандаулыдан чыккан яшь кояшның
Тәү нурлары төшсен ташыма.

Исеп торсын миңа җәен, кышын
Авылымның төрле җилләре.
Күренеп торсын тәүге буразнама
Ялан тәпи баскан эзләрем.

Күренеп торсын минем Агыйделем,
Печән чабып, җыйган болыннар.
Туганнарым белән урак урып,
Чәй кайнатып эчкән урыннар.

Ишетелеп торсын Акчишмәнең
Татлы җыры, салкын тавышы.
Үрчокырдан Әрәсазга кадәр,
Гомер кебек, кыска агышы.

Ишетелеп торсын кешеләрнең
Сөйләшкәне туган телемдә.
Шул тел, шул моң әле яшәгәндә,
Яшиячәк минем исемем дә.

Үлгәч, мине җирләсәгез иде
Үрбашыдан карап бер урын.
Башка җирләр мине онытса да,
Онытмас, дим, бу җир үз улын.

ИСКЕ ЕЛНЫ ОЗАТКАНДА

Әллә ничек авыр булды бу ел —
Бәйрәмнәрдән башлар чыкмады.
Гомерлеккә дигән дуслыклар да
Бокал чыңнарында чатнады.

Алла гына белә табыннарда —
Кайда ялган, кайда дөреслек.
Кеше алдында әдәп саклау, имеш —
Күрешмәстән килеп күрештек,
Ә, җитмәсә, уйнап-көлештек.

Бу дөньясы шулай корылганмы,
Мин генәме аңсыз, бер ахмак!
Кичә аның ул гайбәтен сатты,
Бүген алган аны кочаклап.

Бер-береңә нинди елмаюлар!
Кайда куйдык алар кадерен?!
Шул елмаю аша шул күзләрдә
Ихласлыкның күрәм каберен.

Табигыйлек! Синең саф чишмәләр
Корып бара мәллә йөрәктә.
Ясалмалык! Алып керәсең бит
Сарайларда булган гадәткә!

Өйрәндекме туеп сикерергә,
Шатлыккамы күңел күнеккән.
Кыенлыклар онытылып бара,
Әзер бәйрәм керә ишектән.

Җиңел күтәрелә авырлыклар —
Көч-гайрәткә хәйран калырлык.
Ә үзебез эзләп интегәбез
Юк нәрсәдән мәгънә, авырлык.

Язганым да әнә шуңа охшаш,
Үзем дә шул бер үк чамада.
Зур югалту булмас, төшеп калсам,
Әгәр шундый төпсез чанадан.

Авырлыклар авыр күтәрелсен,
Җиңеллекләр иде екмасын.
Әллә ничек авыр булды бу ел,
Бәйрәмнәрдән башлар чыкмады.

МИН ОЗАТАМ...

Мин озатам сине... Үзем инде
Көтәм синең кайтыр көннәрне.
Мин озатам... Синең белән бергә
Озатам мин көзге җилләрне.

Җил туздыра агач яфракларын,
Җир сап-сары, һава сап-сары.
Мин озатам көзне... Үзем инде
Көтәм яфрак ярыр чакларны.

Олпатлана төштем кебек инде,
Сабырсызлык хәзер ят кебек.
Ә күңелем һаман тезгеннәрен
Чәйнәп өзеп чапкан ат кебек.

КИЧӘ ҮЛСӘМ...

I

Тәүге кар бу! Дөнья ап-ак! Бер әкият
Һәр минутың, һәр сәгатең, һәрбер көнең!
Әй кар ява! Кар түгел бу, ак нур ява —
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

II

Әй, кара күз! Шушы ап-ак җир йөзендә
Карап минем күзләремә: «Сөям!» — дидең.
Кара күзләр! — Кара урман, ап-ак хыял,
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

III

Фани дөнья, нигә соң син мәрхәмәтсез.
Явызларың һаман туып тора синең?!
Ак бәгырьгә кара агу сипте берәү —
Кичә үлсәм икән, бүген күрмәс идем.

IV

Шатлык керде, бәйрәм керде дус өенә —
Яхшылыклар гел тантана итсен! — димен.
Дус өеннән керде бәйрәм минем өйгә,
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

КӘККҮК ТАВЫШЫ

Габәши каберен эзләп,
Тимер Арслан белән
Без зыяратта йөрибез...
Тирә-як — яп-яшь үлән...

Еллар, еллар... Без окоплар
Казыдык җирдә ул чак.
Ә монда бер чит кешегә
Кабер казыган Чалкак *.

Һәр кабер — җирнең ярасы,
Ябылмый торган яра.
Кайда соң ул? Кешедән бит
Кабер булса да кала?!

«Кайда?» дип эзләп, сорап,
Йөрибез урап-урап...

Чү! Янәш кәккүк чакыра,
Елларны санап-санап.
Ул чакырмый, ул моңлана
Татарча, башкортчалап.

Әй ул моң, җыр якын кебек
Тик безгә, безгә генә.
Хуш, Чалкак!.. Кәккүк тавышы
Үзәкне өзә генә.

---

* «Кәккүк» дигән мәшһүр җырның авторы композитор Солтан Габәши Борай районы Чалкак авылында күмелгән.

ТАҢ АЛДЫННАН ӘЙТЕЛГӘН ШИГЫРЬ

Таң атарга калды өч сәгать,
Өч сәгатьтән инде китәсең.
Өч сәгать — ул миңа өч минут,
Өч минуттан ялгыз итәсең.

Син китәсең... Кала якты көн,
Якты көндә калам көн күреп,
Кала кояш, ләкин китәсең,
Йолдызларның барын сүндереп.

Кояш баер, янар йолдызлар,
Кабатланыр таңнар яңадан.
Кабатланыр көннәр, сәгатьләр,
Булыр ай, ел шулар санынннан;

Кабатлана барыр мизгелләр,
Кабатланыр гореф-гадәтләр —
Кабат килеп, кабат китәрсең,
Ә тик
Кабатланмас шушы сәгатьләр —
Гомернең бер алтын кисәге,
Иртәгә ул инде кичәге...

ГАРМУН

...Әлдә гармунчы түгелмен,
Уйнар да елар идем.

Мостай Кәрим.

Кулларыма алсам сине,
Билләрең бөгелмәле.
Бер сыздыру белән моңың
Күңелгә түгелмәле.

Биш яшьлек чагымның бармак
Эзләре телләреңдә.
Тәү уйнаган көйләр чыңы
Һаман да йөрәгемдә.

Моңыңда — туган җиремнең
Кояшлы тарафлары,
Абыйларымның яшьлеге,
Әнием карашлары.

Яшьлекләр дә, карашлар да
Сүнделәр инде күптән.
Ә синдә һаман шул ук моң,
Тик уйнаучылар бүтән.

Юк синдә һич ялган тавыш,—
Кушылып җырлыймын да.
Ярый гармунчы булганмын,
Елыймын, уйныймын да.

* * *

Бервакыт та ялгыз калмадым мин
Юлларда һәм өйдә, табында.
«Ялгызмын шул...» — дигән чагымда да
Эт булса да булды янымда.

Ул юк икән — я агачлар белән,
Я үләннәр белән сөйләштем.
Алар булмасалар, күктә янган
Мин йолдызлар белән серләштем.

Аларны да болыт каплаганда,
Күңелемнең ярып томанын,
Минем белән иде шигырьләрем —
Мин бервакыт ялгыз булмадым.

НИНДИ КӨН БУ?..

22 июнь 1969 ел

Онытырлыкмы соң сине,
Июнь таңы — якшәмбе көн.
Җирне чорнап алды синдә
Ут һәм төтен, ут һәм төтен,
Сугыш туган каһәрле көн.

Шул утларның сүнгәненә
Күпме гомер үтте инде.
Сугыш туар төсле һаман
Шушы көнне, шушы көнне,
Күпме гомер үтте инде.

Тагы июнь... Бүген менә
Егерме дә икесе көн.
Сабантуе буласы көн,
Моржалардан чыга төтен
(Туры килгәч килә бит ул —
Көне дә бит якшәмбе көн).

Ләкин бүген иртәдән үк
Яңгыр коя, коеп түгә.
Яңгыры да шундый көнгә
Килгәч бит ул туры килә.

Бөтен халык өй эчендә,
Яланда тик йөри маллар.
Серәешеп тора өйдә
Кичә җыйган тастымаллар.

Көтүләргә чыкмый калган
Сарыкларның сайланмасы.
Батырлар да сизеп тора
Көннең бик тиз җайланмасын.

Малайларның күзе тышта,
Кычый аяк табаннары.
Яңгыр коя... Су эчендә
Чабыш, көрәш мәйданнары.

Нинди көн бу?! Шатлыклардан
Кешеләрне мәхрүм итте.
Кемдер, каһәрли-каһәрли,
Яңгырны һәм көнне сүкте.
Ә көн үтте... Имин үтте.

ГАРМУНЧЫ КЫЗ

Эзләп табарлык та түгел
Сәбәбен аның, дуслар:
Бездә юк, дисәң дә ярый,
Гармунчы хатын-кызлар.
Бар ир-атка уч иткәндәй,
Күңелгә биреп бер ямь,
Китте авылда беренче
Гармунчы булып Мәрьям.
Кайда Мәрьям — шунда гармун,—
Фермада, болыннарда;
Гармун моңы — кич клубта,
Туйларда, табыннарда.
Гармунчы егет дигән дан
Сүнәр дип тормадылар,
Гармунчыны җырга кушып
Егетләр җырладылар:
«Ал Мәрьямем, гөл Мәрьямем,
Ал гөлләрнең бәйләмен.
Күзгә кадәр, туйга кадәр,
Рәхәт үтсен җәйләрең...»
Җәйләр үтте, күзләр җитте,
Туйлар да булды көйле.
Егетләрдән берәү генә
Мәрьям янында иде.
Туйдан соң да кайда Мәрьям,
Шунда гармун, шунда моң.
Берәр туй я берәр уен
Гармунсыз үтәме соң?
Сыздырып җибәрсә Мәрьям,
Җилкенеп куя күңел.
Уйнавы да, каһәр төшкән,
Һич тә ирләрчә түгел.
Уйный күзләр, уйный кашлар,

Уйный гәүдә, уйный тән.
Шул чакта тыныч булырмы
Ирмен дигән бирәр җан.
Үлгәне дә тереләдер,
Сүнгәне — кабынадыр.
Шәйләми бассаң бу хәлдә,
Йөрәк тиз абынадыр.
Биетә Мәрьям ирләрне,
Тик бирәү авыз ера,
Мыек астыннан елмаеп,
Мыегын борып тора.
«Нигә биемисең? — диләр,—
Беттеме көч, әллә чәм?»
«Мине,— ди ул,— гармунсыз да
Биетә өйдә бичәм».
Ә бичәсе Мәрьям атлы —
Беренче савучыдыр.
Беренче хатын. Авылда
Беренче гармунчыдыр.

КИЧӘГЕ ХӘЛДӘН СОҢ ДУСКА ӘЙТЕЛГӘН СҮЗ

Чәнчелеп китсен барсы да —
Барысына төкер.
Табигатьнең үз законы —
Аллага шөкер.

Сиңа күбрәк бирелгән —
Шуны белсеннәр,
Сиңа түгел, үзләренә
Үпкәләсеннәр.

Кешеләр әле һаман да
Мәкерле, усал.
Бер-берсенә ачалар
Рәхимсез китал *.

Ә җирдә күпме яхшылык —
Нинди саф һава!
Бернинди мәкерсез-нисез
Җилләп кар ява.

Чәнчелеп китсен! Җирдә бит
Кар бар, җилләр бар!
Алда әле кар астыннан
Чыгар гөлләр бар.

Шул гөлләр өчен генә дә
Яшәргә мөмкин.
Киң булса әгәр күңелең,
Дөньялар иркен.

Булсын яшәү таянычы —
Акыл һәм йөрәк.
Явызларга яшәр өчен
Мәкерлек кирәк.

Чәнчелеп китсен! Булыйкчы
Табигать яклы!
Гомер бакый булган адәм
Эреле-ваклы...

---

* *Китал* — сугыш.

* * *

Төн уртасы. Саф, аяз төн...
Саф тынлыгы кергән өйгә.
Шул тынлыкта һич туктаусыз —
Ләң-ләң, ләң-ләң — бер эт өрә.

Тирә-якта юк тавыш-тын,
Ә ул сизә, күрә бугай.
Нигә өрә, кемгә өрә —
Үзе генә белә бугай.

Илаһи төн, илһамлы төн,
Ай-йолдызлар бии гүя.
Йолдызларга өрәме ул,
Әллә микән Айга өрә?

Әллә, димен, чыгып үзен...
Нигә әле күренергә?..
Өрсен әйдә! Эт өргәнгә
Вакыттыр бит күнегергә.
О, юк!..

ЮККА ТҮГЕЛ, ЮККА ТҮГЕЛДЕР

Кайда барма — җирдә матурлыклар,
Без — шул җирдә туып үскәннәр.
Безгә кадәр, безгә кадәр дә бит
Җиргә күпме килеп киткәннәр.

Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул
Яшьнәү-күкрәүләргә тиң гомер,
Бу дөньяга без килгәнбез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер!

Бер үк кояш һаман караса да,
Бер үк булмый заман җилләре,
Йолдыз белән йолдыз арасында
Балкып ята кеше эзләре.

Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул
Яшьнәү-күкрәүләргә тиң гомер,
Бу дөньяда без яшибез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер!

Безнең өчен җирдә гөлләр үсә,
Карлар ява, җилләр исәләр.
Син ышанма, үзе өчен генә
Мине әгәр яши дисәләр.

Без күз ачып йомган ара гына —
Безнең бергә үткән бу гомер.
Бер-беребезгә без кирәкбез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер.

* * *

Дөньяда сер бетеп бара сыман...
Хәтта менә ике арада —
Әйтелгән сүз сер булмауга дучар —
Җәһәт оча, китә, тарала...

Дөньяда сер бетеп бара сымак...
Серсез кебек җир-күк, бар галәм.
Ай тапталды, Зөһрәдә юк гыйффәт,
Юкка чыкты оҗмах, җәһәннәм.

Юкка чыкты гасырлардан килгән
Төрле хыял, фараз итүләр.
Тормыш тулы могҗизалар белән,
Шуларга да күнә кешеләр.

Бер ысулда уйлап чыгарулар
Машинасын яки шигырен.
Акыл үсә, күңел корый төшә —
Шигырьдә дә «акыл» шыгырым.

Дөньяда сер бетеп бара сымак...
Зинһар, җирем, серсез калдырма,
Кеше күңеле серле могҗизадыр,
Шул могҗизадан мине яздырма!

СОҢГЫСЫДЫР КЕБЕК

Ни кылсам да, соңгысыдыр кебек,
Соңгы кебек бу юл йөрүем.
Ул юлларда күпме кешеләрне
Булган икән соңгы күрүем?

Соңгысыдыр кебек соңгы хатам,
Гүя соңгы тәүбә ителде...
Шатлыкларым да чын шатлык кебек,
Кайгыларым да чын шикелле.

Соңгысыдыр йөрәк яраларым,
Күз яшемнең энҗе бөртеге.
Соңгы тапкыр аңдып тора төсле
Дошманымның соңгы этлеге.

Бөтенесе дә соңгы булып калсын —
Үтелгән юл булмый соңгысыз...
Юк, күңелем, алдан фараз итмә —
Әйтелмәгән әле соңгы сүз.

* * *

Кылган эшләр төрле... Шул төрледән
Дус шатлана, дошман шатлана.
Дошманыңны шатландыру җиңел,
Шатлыклардан менә
Мәхрүм булып бик еш дус кала.

ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

* * *

Синең алда булсам, дидем, акыллырак,
Булыр идем башкалардан матуррак.
Тик гел мәхрүм идем акыл алтыныннан,
Чөнки сине сөйдем язып акылымнан.

* * *

Дөреслеккә гомер табындылар...
Мин дә аннан, башым иеп, сабак алдым.
Бары тик бер явыз хакында мин
Гел дөресне сөйләп хаталандым.

* * *

Бу дөньяга мин пакь килеп кердем,
Саф чишмәсе булып өметнең.
Хәзер инде бер зур кала аша
Агып үткән елга кебекмен.

* * *

Һәрнәрсәнең чиге булмый булмый —
Чикли ала адәм ут юлын.
Сине күргәч кенә аңладым мин
Матурлыкның чиге юклыгын.

* * *

Сугыштан да яман нәрсә юктыр,
Лаектыр ул мең-мең каһәргә.
Ә шулай да ул өйрәтте безне
Ничек үләргә һәм яшәргә.

* * *

Акыл дисәң, аңкып тора синнән!..
Сере кайда шундый булуның?
— Акылсызлыгыңны кешеләрдән
Яшерә бел — сере шул аның.

* * *

Бөтен нәрсә утта әрнеп кыза,
Әрнеп янып, ката соңыннан.
Минем йөрәк сиңа бер таш икән,
Ул да әрнеп, янып суынган.

* * *

Шигырь язган һәркем шагыйрь түгел —
Һәр очкан кош түгел ул лачын.
О могҗиза! Адым саен түгел,
Гасыр исәбенә туасың.

* * *

Хакыйкать ул — яп-ялангач,
Яңа туган бала төсле,
Үзе көчле. Көче тиңсез,
Ләкин көчсез синсез, минсез.

* * *

Дошманым бар. Аның булуыннан
Һич курку юк — хәтта мин тыныч.
Ләкин аның белән бер кашыктан
Ашаган дус — үтә куркыныч.

* * *

Югалтышып беттек,— булган инде,—
Әллә чынлап, әллә юри кыландык без.
Беребездән беребезне югалтмадык,
Үзебездән үзебезне югалттык без.

* * *

Якыныңа, иң кадерлеңә дә
Күңел кайчак җитәр-җитмәле —
Авыртмаса, бик үк беленми шул
Йөрәкнең дә кайда типкәне.

* * *

Тау җимерер кебек идем бүген...
Тирбәлде көн алтын сиртмәдә.
Үтте көнем. Хәзер мин ул тауны
Җимерермен кебек иртәгә.

ИБЛИС

Поэма

Кереш

Кыя таулар... Кыя киртләчендә
Вәйран кальга — иске ныгытма.
Ишек-тәрәз тишегеннән керепЧыгып йөри җилләр, болытлар.
Монда адәм аяк басмаганга
Күпме гомер, күпме ел үткән.
Борма-борма менгән тар сукмакны
Үлән басып киткән, нур өткән.
Ә ул тора тишек күзе белән
Заманнардан карап заманга.
Үткәннәрдән бүгенгегә карый,
Яхшылыкка карый, яманга.
Ул төзелгән... Түгелгәндер монда
Тир дә, кан да һәм күз яше дә.
Ул төзелгән... Монда чәкәшкәндер
Төрле язмыш күкрәп, яшенләп.

Ул төзелгән... Кеше төзи, төзи...
Мин дә шулай гомерем буена,
Яныпяныптөзеп куйдым кебек
Шигырьләрдән торган бер бина.
Ул бинамны һаман төзим әле
Иртәгә һәм бүген өчен дә.
Иртәгәләр бүген туа икән.
Шул иртәгәм бармы бүгендә?
Ә булмаса — бинам ишегеннән
Йөрер микән җилләр, болытлар.
Күренерме тишек күзләреннән
Дөнья сере һәм киң офыклар?
Нинди очкын, нинди нур калыр соң
Сынында һәм шигъри йөзендә?
Үлән басар микән сукмакларын
Башка телдә, башка мизгелдә?
Язам менә... Вәйран кальга тора
Күз алдымда... Тора күңелдә.
Үзем язам, ә үземдә сорау:
Иртәгәм соң бармы бүгендә?

Беренче бүлек

I

Утыра Иблис Минә * тавында
Я көлеп, я коеп күз яшен.
Күз яшенең һәрбер тамчысы
Тама тауга булып ут-яшен.
Ә көн аяз. Шундый аяз көн!
Нурдан кыза, яна җир өсте.

* Согуд Гарәбстанындагы Мәккә каласыннан ерак булмаган тау. Хаҗга баручылар шул тау итәгендә корбан чалалар.

Гарәп җире соры таш та ком,
Суынмаган утлы көл төсле.
Утыра Иблис Минә тавында,
Фанилекләр моннан тайганнар.
Тау астында мыжгый, гөж килә
Адәм заты белән хайваннар.
Акырыш та монда үкереш,
Адәм гүя хайван төсендә.
Һәр ике зат беткән буталып,
Монда иман иман эчендә.
Ике зат та монда буталган,
Икесе дә монда корбаннар:
Адәм исә — иман корбаны,
Адәм өчен корбан — хайваннар.
Барысына монда бер иман,
Юллар килеп бергә төйнәлгән.
Көнчыгыштан яки көньяктан,
Көнбатыштан яки төньяктан
Күзләр килеп монда төбәлгән.
Бергә монда сары тәнлесе,
Ак тәнлесе яки карасы.
Беткән монда төсләр арасы,
Яшь арасы, телләр арасы.
Утыра Иблис Минә тавында,
Монда иман иман эчендә.
Бу урында һәм бу сәгатьтә
Хәтәр хәтта Иблис өчен дә —
Иблис көчсез... Уйный ут-яшен —
Утыра Иблис, түгеп күз яшен.

II

Утыра Иблис Минә тау башында,
Ә шул тауга табан, көньякка,
Килде Әхмәт. Килде, килде Әхмәт
Кыйбласына карап төньяктан.

Утыра ул соры таш өстендә —
Ә таш ята төрек җирендә.
Утыра Иблис Минә тау башында,
Минә тавы гарәп илендә.
Әйтерсең лә тыны белән тартты
Минә тавы, Мәккә Әхмәтне.
Әхмәт өчен изге булса да юл,
Кайда да бер юлның михнәте.
Утыра Иблис Минә тау башында...
Минә белән Әхмәт арасы —
Таулар аша, сулар, чүлләр аша
Барасы да әле барасы...
Таш өстендә таштай каткан Әхмәт,
Юлныңмы бу әллә азагы?
Ә дәвамы ничек? Чынлап микән
Юл газабы — ул гүр газабы?!
Ул аңлый да, аңламый да төсле
Язмышының мондый тиклемен.
Сөю белән нәфрәт арасында
Ул тукталып калган шикелле.
Ә бармы соң сөю? Кайда нәфрәт?
Нәфрәте бар, нәфрәт — юл башы.
Тик шул нәфрәт алып килде монда,
Тик шул нәфрәт булды юлдашы.
Юлның башы — яшел Зөя буе —
Әхмәт тәпи баскан үләннәр.
Уйнап үскән урам, су буйлары,
Болынлыклар, басу, үзәннәр.
Килде Әхмәт... Көн-төн килде Әхмәт,
Үз нәфрәте белән юанып.
Зөя буе, туган җире калды
Кара томан-төнгә уралып.
Төньягыннан төнен китте Әхмәт,
Үзен-үзе куды еракка,
Туган җирдән карак кебек качты,
Котылам дип бөтен гөнаһтан.

Әхмәт күңеле ярсу аттай иде:
Өзгәләнде, шашты, дулады.
Мәчет ябык. Манарасын кисеп
Төшерделәр... Бетте ул... Ауды.
Егылды көч, егылды бар иман,
Азан тынды авыл өстендә.
Уйлады ул: «Калды,— диеп,— дөнья
Төн эчендә, гөнаһ эчендә».
Таш өстендә таштай каткан Әхмәт...
Бер чиге юк төсле уеның.
Күз алдында, һаман күз алдында
Соңгы төне Зөя буеның.
Төн ягыннан төнен качты Әхмәт,
Утын арбасына төянеп.
Әйберләрен, балаларын төяп,
Ат артыннан җәяү ияреп.
Авыл йоклый иде... Тик бер йортның
Тәрәзендә генә ут янды.
Төн эченнән шул ут, бер ут кына
Балкый төсле иде дөньяны.
Кем утырды авыл Советында
Шулай соңлап, эшен төгәлләп?
Әхмәт китте... Шул ут аңа һаман
Арттан килде төсле эзәрләп.
Әхмәт китте... Ә ут арттан куды,
Ә ул уттан качты шикелле.
Әхмәт куды атын... Төн әйтерсең
Әкрен-әкрен эреп тишелде.
Таң — таң түгел, ә төн — тик төн булып
Калды аңа таулар артында.
Ул шул төннән чыккан кебек кенә
Тойды үзен бу таң каршында.
Ат атлаган саен тәгәрмәчләр
Җирдә тап-тар эзләр суздылар.
Ул тар эзләр, Идел буйлап килеп,
Дон даласы аша уздылар.

Аунаклап та, шыгырдап та алар
Әйләнделәр диңгез яр буйлап.
Ул эзләрне җил-яңгырлар юды,
Ә менә тик... Әхмәт ни уйлап
Таш өстендә таштай каткан хәзер?
Озаккамы? Шушы минутлар
Көннәр, айлар, еллар кебек озын...
Нигә әле озын? Чит утлар
Йөрәгенме сала сагышка?
Юк! Берсе дә юк! Хәтта түгел
Акыл белән җаны алышта.
Таш өстендә таштай каткан Әхмәт —
Күз алдында кабер — кара гүр.
О, ул кабер — килгән юлы буйлап
Булса икән әмма бердәнбер!..
Юл башында алар җидәү иде,
Нәкъ җиде җан иде арбада:
Үзе, остабикә, дүрт малае,
Җиденчесе — сылу кыз бала.
Алар җидәү иде — җиде йөрәк,
Сигезенче бала — карында.
Юл буенда дүрт гүр-кабер калды:
Беренчесе — Идел ярында,
Икенчесе — дала куенында,
Өченчесе — диңгез янында,
Дүртенчесе... Нигә әле санау,
Кирәкме соң саннар исәбе?
Үтелгән юл һәм дүрт йөрәк ята —
Һәрберсе кан һәм җан кисәге.
Таш өстендә таштай каткан Әхмәт:
Күз алдында кабер... Бишенче...
Ул ни әйтсен: язмыш, дисенме дә,
Яки, гаеп миндә, дисенме.
Кызы ята утын арбасында,
Ана — җирдә. Авыр тын ала,
Аны тулгак тота... Үрсәләнә:

«Нигә туа икән бу бала?!
Шулар белән бергә үлсәм икән,
Каһәрнең дә бардыр бер чиге.
Кайда соң ул хаклык дигән бина,
Ничек ачыла соң ишеге?
Тезелеп дүрт кабер калды артта,
Кайтыр юлга маяк өченме?
Алар үлеп калды, туган җирдән
Без китмибез, дигән шикелле.
Нигә киттек? Нигә киттек әле?
Куылгандай йорттан эт кебек.
Көннәр, айлар килдек җир өстеннән,
Без шуышып барган корт кебек.
Кайда барабыз без? Нинди гөнаһ
Алып китте безне шулкадәр?
Изгеме соң бу юл? Изге булса,
Төшмәс иде башка бар каһәр!»
Таш өстендә таштай каткан Әхмәт,
Таш шикелле баш та, йөрәк тә.
Үрсәләнә җирдә Бибикамал,
Үзе гүя тере үләксә.
Бу сәгатьтә яшәү белән үлем
Тотышалар төсле шобага.
Берсе китә, икенчесе килә,
Уч иткәндәй килә дөньяга.
Кеше туа... Үлә... Гади төсле
Табигатьнең бөтен кылганы.
Көн белән төн, төн белән көн килеп,
Алмашынган төсле нибары.
Үрсәләнә җирдә Бибикамал:
«Нигә туа икән бу бала?!
Изгеме соң бу юл?! Каһәрнең дә
Чиге бардыр, бардыр дөньяда!..»
Әйтерсең лә таштай каткан Әхмәт
Шартлап китте шул чак кинәттән —
Бу куркыныч тавыш кайдан чыкты,

Таштанмы ул, әллә йөрәктән?
Яңгыратып бөтен уйсулыкны,
Ике кулын күккә күтәреп,
— Ләгънәт! — диде,— җир йөзенә ләгънәт! —
Һәм шунда ук, җиргә төбәлеп,—
Синдә Иблис! — диде хатынына,—
Сине Иблис, Иблис котырта.
Исмәгыйльне * шиккә салган кебек,
Шиккә сала сине, куркыта!..—
Җирдән җыеп алып тирә-якка
Ул вак ташлар бәрде укынып.
Җил искәндәй булды. Килде тавыш:
— Бәрмә, бәндәм, хәл ит утырып.

Әхмәт
Кем син?

Иблис
Мин.

Әхмәт
Кем соң ул — мин?

Иблис
Син түгел.

Әхмәт
Әллә?!

Иблис
Әйе.

---

* *Исмәгыйль* — дини легенда буенча, Ибраһим пәйгамбәрнең улы. Ибраһим пәйгамбәр, үзенең төшенә ышанып, Исмәгыйльне аллага корбан итәргә Минә тавына барганда, улы атасына: «Алла чынлап та мине сорадымы?» — дигән. Ата шулвакыт: «Сине Иблис котырта»,— дип, янәсе, Иблисне куар өчен, тирә-ягына вак ташлар ыргыткан.

Әхмәт

Кит! Кит!

Иблис

Кирәкми!

Бәрмә ташлар... Мин бит синдә! Сездә!
Миңа тими алар, эләкми.
Ибраһим да шулай ташлар атты
Исмәгыйльдән мине куам дип.
Яшь Исмәгыйль уйлагандыр бары,
Нигә әле корбан булам, дип.
Дөрес уйлаганмы? Ышанмаган
Атасының, димәк, төшенә.
Ярый әле шунда алла түгел,
Кешелеклелек җиңгән кешедә.

Әхмәт

Аллага ни әйтереңне беләм —
Син бит, Иблис, усал һәм көчле.
Күктән җиргә куылганың өчен
Аллага бит мәңге син үчле.
Ходайга ни әйтереңне беләм.
Булмаганда әгәр син, зәхмәт,
Җир гөнаһсыз, без гөнаһсыз булып
Яшәр идек.

Иблис

Тукта син, Әхмәт!
Әйе... Мин куылган... Мине күктән,
Оҗмахыннан алла кудырган.
Ә бит көчле адәм, көчсезлеген
Аклар өчен, мине тудырган.

Әхмәт

Сине адәм тудырмаган! Юк! Юк!
Синме, Иблис, адәм затыннан?

Иблис

Түгел... Ә мин синдә туган! Синдә!
Кая барма синең артыңнан
Калмыймын мин. Кем соң үз рухыннан
Кача алган борын-борыннан?

Әхмәт

Ә мин качтым.

Иблис

Кемнән? Рухыңнанмы?

Әхмәт

Син гөнаһлы иткән урыннан.
Синнән качтым.

Иблис

Юк! Син үз-үзеңне
Кудың бары туган җиреңнән.
Син беренче куркак! Чыга алмый
Кабыгыңнан, юка тиреңнән,
Аны саклап калыр өчен генә
Син сайладың шушы юлыңны.
Шушы юлда харап иттең менә
Бер кызыңны һәм дүрт улыңны.

Әхмәт

Җитте! Минем балаларымда соң
Ни эшең бар?! Алар гөнаһсыз!
Изге юлның корбаннары алар,
Ә андый юл булмый корбансыз.

Иблис

Корбан?! Һәрбер үлем корбан түгел,
Аларны син, тик син үтердең.
Үтерүче!..

Әхмәт

Юк! Син үтерүче,
Ул син алдың котын бу җирнең.
Ул син салдың кеше йөрәгенә
Төрле коткы, төрле дошманлык.
Дөньяның бит асты өскә килә,
Басты ялагайлык, куштанлык.
Ата — улны, ана кызны белми,
Бетте әдәп, бетте бар иман!

Иблис

Нигә бетте? Нигә бетердегез?!
Син үзең бит, үзең бер имам.
Бөтен авыл, бар мәхәллә рухы
Синдә иде,— их син, дивана! —
Рухны кулда тотудан да зур көч
Бармы сезнең фани дөньяда?!
Үз гаскәрең үз кулыңда иде,
Ә рухны кем ансыз тоталган?
Ә син охшаш, бар гаскәрен ташлап
Качкан генералга, имамга.

Әхмәт

Имам... Имам!.. Имамнарның да бит
Ниндиләре генә булмаган!
Шамил нинди имам иде дә бит,
Ничек китте җирдән, дөньядан?
Ул да шушы минем барган юлдан,
Әсирлектән — данлы коллыктан
Башын алып качмаса да, ә бит
Җанын алып качты хурлыктан *.
Ул да куркакмыни?

---

* Шамил, тарихи мәгълүматлар буенча, җиңелгәннән соң әсирлеккә төшкәч, егерме биш ел Калугада яшәгәннән соң, Мәккәгә барып үлә.

Иблис

Хурлыктан да
Бармы җирдә башка түбәнлек?
Ул бит әсир иде.

Әхмәт

Миңа язмыш
Тордымыни, оҗмах бирәм, дип?

Иблис

Юк, янәшә куйма! Сезнең ара —
Җир белән бит ул күк арасы.
Шамил — бер тау таулар арасында,
Җир агасы, ул — ил агасы.

Әхмәт

Әйе, ил агасы... Зур гаскәрле...
Бер мәхәллә генә түгел бит.

Иблис

Эш зурда я бәләкәйдәмени?
Аның бер исеме үзе бит,
Гаскәр көче, гаскәр рухы булып,
Курку салды дошман җанына.
Куркакларга андый исем килми,
Бирелсә дә килми җәбенә.
Ике таш бар Рәсәй киңлегендә,
Берсе аның ята көньякта,
Кара-койсу ярсып аккан җирдә,
Таулар арасында аулакта.
Икенчесе тыныч агып яткан
Нева-су буенда — шималда *.

---

* *Шимал* — төньяк.

Падишаһка һәйкәл ителгән бер
Кан өстендә торган храмда *.
Икесе дә Шамил әсир булган
Сәгатьләрне сөйли.

Әхмәт
Бу — хурлык!
Ә мин әсир түгел. Мин — иректә!

Иблис
Бу иреклек түгел — горурлык.
Ден дошманның алтын храмына
Булган икән әгәр язарлык,
Җиңелү дә бәләкәйдән түгел,
Сабак биреп, сабак алырлык.
Храмнарга язылыр исем икән,
Димәк, аңа лаек булырлык.
Һәр җиңелү әле хурлык түгел,
Һәр җиңү дә түгел горурлык.
Әсир итү бик үк җиңелмени!
Көчле булган, димәк, Шамилләр.

Әхмәт
Көчле булгач, нигә җиңелгәннәр?
Акланырга юк бит дәлилләр.

Иблис
Нигә акланырга?! Акланулар
Бу урында яман, нигезсез!
Һәр коллыкны һәм һәр кол итүне
Аклыйсыз бит... Нинди заттан сез?!

---

* Сүз үтерелгән Александр II патшаның каны аккан урында төзелгән храм-һәйкәл турында бара.

Әхмәт

Ходай белә... Мин ходайның колы.
Мин азатмын башка коллыктан.
Асты өскә килеп бетәчәк җир,
Иман беткәч, ходай юклыктан.

Иблис

Ләкин син Ватансыз!

Әхмәт

Булсын! Миңа
Кирәге юк андый Ватанның.

Иблис

Болай булгач, нигә Иблис диеп,
Бер мин генә икән аталдым?

Әхмәт

Тукта! Монда иблислекне Иблис
Фашлый түгелме соң? Бу ни хәл?

Иблис

Синең җаның — рухың кирәк миңа!
Мин бит синсез көчсез!.. Мин бик җәл!..
Безнең язмыш уртак — икебез дә
Куылганнар моннан, тегеннән:
Мин куылган күктән шушы җиргә,
Ә син — күккә шушы җиреңнән.
Арбаң эзен күрәм җир өстендә,
Сәфәреңнең күрәм газабын!
Аның башын күрәм һәм шулай ук
Мин юлыңның күрәм азагын.
Ә ул оҗмах!.. Ха-ха!

III

Таш өстендә таштай каткан Әхмәт...
Әче тавыш китте яңгырап:
— Нигә җирләмисең? Бала туа,
Мәеттән ул тормас җан сорап.
Аның үз җаны бар! Бала!.. Безнең
Газапларның соңгы варисы.
Бала туа! — диде Бибикамал,—
Бар, эзләп тап кендек әбисен!
Аңына чак килде кинәт Әхмәт...
Читлектәге хәлсез кош кебек,
Сугылды бер монда, бер тегендә...
Барысы бер яман төш кебек...
Ул кычкырды: «Ярдәм!!» Әхмәтнең дә
Бар икән бер үкереп еласы...
Борылып йөгерде ул... Ә тирә-як
Шундый тыныч, шундый илаһи...

IV

Әхмәт китте. Иблис калды ташта,
Туры килгән урыны уртадан.
Бер ягында адәм җиргә туа,
Бер ягында — киткән дөньядан.
«Берәү килә,— ди ул,— берәү китә...
Ә шунда бит нинди гаделлек!
Монда берни, юк, уйдырма түгел,
Ә үзендә күпме гадилек!
Нинди гади адәм яралуы,
Ә мин мәхрүм шундый ләззәттән.
Шул гадилек, шул бер ләззәт өчен
Дәүләтләрдән, бөтен гыйззәттән
Мин баш тартыр идем. Кирәк түгел
Миндәге көч-куәт, шөһрәт-дан.

Ата булыр идем... Ана булып
Бала өчен кояр идем кан.
Әнә ничек үрсәләнә ана,
Мондый сызланулар миңа ят.
Ярый әле миндә бер сөю юк,
Юк бер әдәп миндә, юк оят.
Таныш түгел миңа ана булу
Һәм аталык дигән олы кот.
Нигә Әхмәт торып чапты әле,
Хәтта мине ташлап, онытып?
А, туулар! Тудырулар! Әгәр
Шундый сәләт миңа бирелсә,
Җир тойгысы, адәм тойгылары
Бер нур булып миңа үрелсә,
Җирдә туу бөеклеге өчен,
Бөеклеге өчен үлемнең,
Кеше өчен бер күз ачып йомган
Ара кебек кенә гомернең
Сәгатьләрен, хәтта минутларын
Кабатланмас бөек булганга,
Аларны мин нур-йолдызлар итеп
Сибәр идем бөтен җиһанга.
Туу! Үлү! Ике биеклекнең
Гомер дигән кыска арасы!
Миңа да шул тар арада яшәп
Бер каласы иде, каласы.
Барысыннан тик мин генә мәхрүм,
Шуңа да җир миңа тиң түгел.
Кеше генә җирдә бәхетле бит...
Нигә кеше? Нигә мин түгел?
Адәмнәрнең бәхетләрен күреп,
Мин бәхетсез, усал, ямьмын...
Кеше акыллана бара... көчле!
Ә мин кая, кая барамын?
Ничек булсам, мин һаман да шундый,
Юктыр вакыт, ара исәбем.

Көнем дә юк, төнем дә юк... Үзем
Яшеннәрдән җитез гизәмен.
Нигә шулай? Кайдан хасил булдым?
Нигә кирәк булдым мәдәм мин?
Нинди камил җир йөзе һәм җиһан,
Берни артык түгел, берни ким.
Күрә алмыйм бөтен камиллекне —
Туа әнә... Нигә туа соң?
Һәрбер туу — җирдә бер яңалык —
Шуннан куркам... Куркам! Тумасын!»
Явызлыкка җавап биргән кебек,
Яңгырап китте бала тавышы.
Адәм елап туа... Ах, син якты
Дөнья белән тәүге кавышу!

Икенче бүлек

I

Җиһан мәңге үз хәрәкәтендә —
Әйләнә Җир, көн һәм төн ясап.
Адәм өчен шушы әйләнүләр
Юкка түгел, түгел бихисап.
Бала туганнан соң ничә тапкыр
Җир урады Кояш тирәли.
Мәхмүт атлы егет булып үсте
Юл буенда туган бер бәби.
Тууына Иблис шаһит иде,
Шаһит иде юл, су, туфрак-җир.
Шул туфрак та, туган туфрагы да
Туган түгел иде барыбер.
Туган туфрак — тәнең, җаның аша
Каның тамырланган туфрак ул.
Илең, җирең, телең бергә килеп,
Чорналган бер сихри йомгак ул.

Шул йомгакны сүтә-сүтә килеп,
Сүтә-сүтә яши карт Әхмәт.
Аның өчен торган җире — җәннәт,
Ә йөрәген шул бер нәфрәт
Һаман өтә... Һаман әле үзен
Төннән чыккан кебек тоя ул.
Һаман әле төн эчендә кебек
Зөя буендагы бер авыл.
Элек шуннан намаз саен гына
Кәгъбәсенә багып баш исә,
Шул Кәгъбәнең үзендә ул хәзер —
Пәйгамбәре белән янәшә.
Ул йөрегән сукмаклардан йөри,
Һәрбер тавы изге, һәр ташы.
Үз йортына кергән кебек керә
Кәгъбәнең ул, ачып капкасын.
Пәйгамбәре эчкән чишмәләрнең
Суын ятып эчә ул, тәмләп.
Кая бакма, эссе ком да һәм таш
Әхмәт өчен бу җир — хөр җәннәт!
Дөньялыкка аның исе китми,
Фаниләкләр тора бер якта...
Үз йорты бар монда — нәрсә ул йорт! —
Җаным, ди ул, күптән оҗмахта.
Ә Мәхмүт соң? Ә соң Бибикамал?

II

Мәхмүт үсте томан эчендә.
Хәтта тел дә икәү: өе — татар,
Ә урамы — гарәп телендә.
Өй һәм урам... Бай татарлар салган,
Өч-дүрт өйдән торган тыкырык.
Иман да бер, теләк тә бер монда,
Барысы хөр, ләкин — кысырык!

Киеме белән Мәхмүт гарәп кебек:
Баштанаяк ап-ак җиләнле,
Башында ак шәле, ачык ката
Аягына аның элгәне.
Мәхмүт йөзен кара-саргылт иткән
Гарәп җире, гарәп кояшы.
Ә тик менә аның моңсу зәңгәр
Күзләрен соң кая куясың?
Төньяк төсен хәтерләтә микән
Зәңгәр күзләр, җирән сакалы?
Әйтерсең ул эссе чүлдә үсеп
Тулган ялгыз арыш башагы.
Ул башакның тамырлары кайда,
Аңа туфракмы соң ком чүле?
Әй, мөкатдәс ана күкрәк сөте,
Ана теле, ана күңеле,
Барсы да соң сездән килмимени,
Сез түгелме туфрак, чыганак?!
Бала, бала! Ана күңеленнән
Агып чыккан тере erганак.
Мәхмүт шундый бер erганак төсле,—
Ә erганак ташкын гомерле.—
Үсте Мәхмүт җыр һәм моң эчендә,
Җырлы иде ана күңеле.
Ишетелер-ишетелмәс кенә
«Сибелә чәчкә» эссе чүлләрдә,
Сагышларны кемгә сөйләргә?
«Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә.
Заманалар авыр, юллар ябык,
Дус-иш кирәк дөнья көтәргә».
Әй, моң! Күңел тамырларындамы
Син тере кан булып агасың?!
Ана сөте канга кергән кебек,
Йөрәкләргә сеңеп каласың.

Кайдан яраласың, әйтче син, моң,
Нинди көчләр сине бар иткән?
Һәр халыкның тик үз, үз моңы бар,
Ә бар иткән — җирме, кан микән?
Шул кан, шул җир микән кешеләрдә
Тик үзенчә генә нурлана?
Һәр җырның бит үз ярлары була,
Тик үз яры буйлап моң ага.
Ана җырлый... Мәхмүт йөрәгенә
Агыла җыр әллә кайлардан.
Ераклардан чыңлап килә төсле,
Ата-баба туган ярлардан.
Нинди көч бар сездә, туган моңнар,
Бармы сезгә ерак аралар?
Еллар аша күңелләрме сездән
Күңелләргә күпер салалар?
Ә ул мәңгелектер!.. Ана җырлый
«Ай, аерылмаек, дускаем».
Мәхмүт тыңлый, үз-үзеннән сорый:
«Нәрсә кара урман, куш каен?
Нинди ерәк икән ул Агыйдел,
Ничек ямьле икән буйлары?
Җил искәндә нигә сибелә чәчкә?
Ничек була ул кар сулары?»
Ана җырлый... Җырга кушылмыйча
Мәхмүт күңеле, ахыры, бушамас.
«Кай илләргә барсаң да бер үк кояш,
Туган-үскән җиргә охшамас.
Бөдрә тал (нинди икән ул тал?),
Чит илләрдә йөреп гыйбрәт ал»,
Гарәп иле — Мәхмүт яшәгән ил,
Шул ил генә — күргән, белгәне.
Нигә әле бу чит ил булсын, ди.
Юк бит аның читтә йөргәне.
Чит түгел ул... Ә соң туган илме?
Ул синеке булып калырмы?

Чит булмаган илдә чит булулар
Икеләтә әллә авырмы?
Ана сагышлары тамчы-тамчы
Мәхмүт йөрәгенә тамдылар.
Тамдылар да, шул ук сагыш булып,
Мәхмүт йөрәгендә яндылар.
Ата-баба гомер иткән җирләр
Ана өчен газиз, танышлар.
Шуның өчен ана сагышлары —
Күбебезгә таныш сагышлар.
Мәхмүт исә, еллар, илләр аша
Яра-яра күңеле томанын,
Хыял итте ата-баба җирен —
Ул сагына иде хыялын.

III

Җир сере бар — табигатьнең сере,
Йөрәк сере белән бер түгел.
Җирнең сере бүген ул сер икән,
Ә иртәгә инде сер түгел.
Дөнья читлекләрен тишеп чыгып,
Серләр ача кеше акылы.
Ахыры да бардыр... Ә соң менә
Күңел серләренең ахыры
Бармы соң ул, һәм ул буламы соң?
Һәрбер адәм — үзе бер дөнья.
Кеше күңеле ул шар ачык кебек,
Ләкин анда мең-мең борылма.
Якты киңлек, кара урман да ул,
Көне дә бар аның, төне дә...
Күңеленең нинди борылмасы
Ата-бабаларның җиренә
Борып алып китте Мәхмүт җанын?
Я аңлатып кара, ач серен!..

«Әй туган тел,— ди ул,— әй матур тел»,
Җырлап «әткәм, әнкәмнең теле»н.
Я аңлатып кара — нигә сүнми?
Шул җыр монда ялгыз учак бит.
Ул үләргә тиеш — йөрәгендә
Чит ил дигән салкын пычак бит.
Чишмә дисәк, ул кибәргә тиеш,
Чишмәнең бит башы кайларда!..
Ә җыр очып килгән кебек монда
Тылсымлы кош булып сайрарга.
Шул кош сайрый Мәхмүт йөрәгендә,
Ә куллары чүки калайлар —
Ул калайчы. Гаҗәпләнеп тыңлап,
Карап тора эшсез малайлар.
Осталыкта аның даны чыккан,
Атасы да моңа канәгать.
Тик улының җырын тыңлап, Әхмәт
Дертләп куйды: «Бу ни галәмәт?!»
Җырлый идеме соң? Җырлаганы
Ул нибары моңлы өн иде.
Кулда чүкеч, ә йөрәктә исә
Тукай язган «Туган тел» иде.
Берәү булса, елап җибәрер дә
Алыр иде улын кочаклап.
Ә Әхмәтнең сауды битенә кан,
Ул өенә кайтты аунаклап.
«Изге җирдә, динсез җирнең җыры,
Динсез адәм,— диде,— язган җыр...
Кайдан кергән аңа? Болай булса,
Иманыбыздан соң ни калыр?»
Хатынына ләм-мим сүз әйтмәде,
Җиргә сыялмаган давылдай,
Үз-үзенә сыялмыйча Әхмәт
Кабатлады бары: «Я ходай!..
Әй, ходаем, ярлыка син безне,
Гөнаһлардан безне ит азат.

Качкан идем. Барысыннан качтым,
Нигә тагы миңа бу газап?!»
Күп тә үтми Мәхмүт кайтып керде...
. . . .
. . . .

IV

Әхмәт

Ниткән эш бу?

Мәхмүт

Язык түгелдер.
Гарәпнең дә үз җыры бар, әти,
Бу җыр теле — туган телеңдер.

Әхмәт

Нигә кирәк синең туган телең?!

Мәхмүт

Юк итәргә аны ярамас.

Әхмәт

Ул бит безнең тик йорт теле генә,
Бар сөйләшеп кара, аралаш...
Монда сиңа бер тел — бөек тел бар.

Мәхмүт

Һәр тел бөектер ул үзенчә.

Әхмәт

Бөек сиңа! Монда Коръән теле,
Коръән язылмаган безнеңчә.
Бу бит иман теле. Хак пәйгамбәр
Сөйләшкән бит әнә шул телдә.

Шуның өчен генә дә ул бөек,
Һәм ул дәүләт теле бу илдә.
Нигә кирәк синең туган телең,
Кирәк икән, бар кит — җырласын.
Әнә бара юлың! Чиркәүләрдә
Кафер белән бергә уларсың.
Кайдан бу җыр! Кайдан иңде сиңа?
Нигә эндәшмисең? Телеңне
Йоттыңмы әллә?

Мәхмүт
Юк...

Әхмәт
Нәрсә юк?

Мәхмүт
Телем!
Булса йотмас идем.

Әхмәт
Үзеңне
Шул телеңнән асып куяр идем.

Мәхмүт
Тел үзе дә иман. Ас әйдә!

Әхмәт
Безнекендә нинди иман булсын,
Әтиеңне җирдән һәм өйдән
Нинди телдә сөрделәр соң? Я, әйт?

Мәхмүт
Мин белмимен, ләкин үзеңне,
Бөтен илгә, телгә каршы куеп,
Аклау, әти, дөрес дисеңме?

Һәрбер телнең үз иманы бардыр,
Имансыз тел — тере мәеттер.
Нигә әле, ул син түгел, ә тик
Бөтен адәм, галәм гаепле?

Әхмәт
Ах син, эттән туган, хәзер синме
Газеталар сүзен сөйләүче.
Синме хәзер ходай тәгаләнең
Бер колыннан гаеп эзләүче?

Мәхмүт
Мин дә ходай колы. Ә без болай
Артык колбыз. Колбыз... Кызганыч!

Әхмәт
Әнә бара юлың! Тик бер ходай,
Тик бер ходай — минем ышаныч.

V

Җир бер, өй бер, иман, гаилә бер,
Ләкин гомер бармый бер көйгә.
Нәфрәт, сагыш, хыял бергә иде,
Өч төрле җан иде бер өйдә.
Өч төрле җан... Әхмәттәге — нәфрәт,
Бибикамалдагы — сагышлар,
Мәхмүттәге хыял микән бүген
Яман Иблис белән алышта.
Кемдә мәрхәмәтлек, ә кемдә соң
Яманлыклар итә тантана?
Өч төрле җан... Шушы өч йөрәкнең
Кайсысында Иблис шатлана?
Утыра Иблис Минә тау башында,
Озакламый бу тау астында

Адәм белән хайван тагы килеп,
Буталачак иман каршында.
Ике зат та бәйрәм итәчәкләр,
Бәйрәм итәчәкләр корбаннар.
Иман өчен адәм корбан булса,
Адәм өчен корбан — хайваннар.

VI

Утыра Иблис Минә тау башында,
Уттай кызган Минә тау ташы.
Шушы тауга карап төн ягыннан
Очып килә Әхмәт якташы.
Ак болытлар арасыннан аста
Йортлар, юллар кала күренеп.
Адәм күренми дә... Әхмәт эзе
Күптән инде беткән күмелеп.
Минә тауга карап очып килә.
Бу очулар гаҗәп түгел дә.
Башка очышлар бар... Хәтта изге
Кәгъбә капкасының төбендә
Гарәп журналлары битләреннән
Карап тора көләч Гагарин.
Бөтен дөнья аны алкышлады,
Бөтен дөнья әйтте: «Афәрин!»
Шушы очыш кеше акылының
Йолдызларга иде юл башы.
Кеше кешелеген томалаган
Алла, фәрештәләр дөньясын
Пыран-заран итеп, тамырына
Балта чабу иде тагы бер.
Әхмәт кенә эчтән әйтеп куйды:
«Алла кодрәте ул, барыбер»...

VII

«Әнә бара юлың...» Шушы сүзләр
Чыңлый Мәхмүт колак төбендә,
Ничәмә ай, ничәмә көн чыңлый,
Чыңлап тора менә бүген дә.
Әнә бара юлың... «Ә соң кайда,
Кайда соң,— ди.— Бара минем юл?
Кая бакма — томан... Шул томанда
Юл табуы җиңел түгел шул».
Өйдә тынлык — җимерелгән кашлар,
Ничәмә ай, ничә көн инде.
Күңелләрдә бушлык, авыр тынлык
Өйдән мәет чыккан шикелле.
Моңаймасаң да шул моңаерсың,
Сусаганда эчәр зәлял * юк.
Әнисенә карый Мәхмүт, ә ул —
Әйтерсең лә тере Зиләйлүк.

Мәхмүт

«Сөялгәнсең чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең;
Кызганмыйча күңелем чыдый алмый,
Бигрәк моңлы карый күзләрең».

Бибикамал

Әйтерсең лә безне каргыйсың.
Син моңланма, улым, моңың белән,

Мәхмүт

«Атылган кош, адаштырган эттәй,
Үткәннәргә мәэюс ** карыйсың».

---

* *Зәлял* — салкын һәм тонык су.
** *Мәэюс* — өметсез, өмет өзгән.

Бибикамал
Син елатма мине... Сагышымның
Чиге булыр әле, булыр бер.

Мәхмүт
Һич аңламыйм, энкәй, этигә соң
Нигә яман икән туган җир?

Бибикамал
Без сөрелгән аннан...

Мәхмүт
Кем сөрде соң?..

Бибикамал
Сиңа аңлау — авыр-авырдан.

Мәхмүт
Җырның монда ни гаебе бар соң?

Бибикамал
Җир белән җыр — бер үк карыннан.
Ә, җитмәсә, җырны шагыйрь язган,
Ул — алласыз, әмма бөек җан.

Мәхмүт
Халык җырларында — улмыни соң?

Бибикамал
Халык һәм шагыйрьдә — бер үк кан.
Алар аталы-уллы. Тик синнән мин
Үтенәмен, улым, бүген дә:
Моңлансаң да, эчтән генә моңлан,
Зинһар, тор син атаң сүзендә.
Куркам синең өчен. Аның хәзер
Күзенә ак-кара күренми.

Аңла аны, читкә тибелгәнгә
Йөрәгендә нәфрәт сүрелми.
Берни түгел аңа туган якның
Хәйран калдыруы дөньяны.
Йөрәгенә агу булып тама
Ил уңышы, илнең зур даны.

Мәхмүт

Китәр идем, барып күрер идем,
Төньякларга тарта күңелем.

Бибикамал

Хыялыңны, зинһар, үзеңнән ку,
Аңла моның мөмкин түгелен.

VIII

«Нигә мөмкин түгел? Мин очарлык —
Атылган кош кебек булсам да.
Җирдә эт адашса, кешеләр бит
Адашмыйлар хәтта Җиһанда.
Бу Җир шарын алар бер сәгатьтә
Урап чыга алган чакларда,
Нигә әле миңа ара ерак,
Юллар ерак туган якларга?
Нигә? Нигә?» — Мәхмүт күңеленнән
Тышка ташып чыкты бу сорау:
«Әти,— диде,— канатсызларгамы
Туган илгә кайтыр юл урау?»

Әхмәт

Тик ходаем ярлыкаса иде...
Нәрсә җитми сиңа?

Мәхмүт

Туган ил.
Мин сагынам.

Әхмәт

Син бит үз-үзеңне
Оҗмахыңнан куган Газазил!..
Кайдан хасил синдә мондый уйлар?

Мәхмүт

Үз-үзеннән.

Әхмәт

Юк! Әйт дөресен.

Мәхмүт

Үз-үзеннән хасил... Туган ил — ул
Җанымның бер сихри өлеше.
Миндә, эти, карурманнар шаулый,
Чәчкә ата кырлар, болыннар.
Мин аларны моңнар аша күрәм,
Чакыра мине шушы урыннар.

Әхмәт

Синдә Иблис!

Мәхмүт

Миндә юк ул, эти!
Аллам белән мин ант итәмен.
Карурманнар, болынлыклар аша
Хыялымда гына үтәмен.

Әхмәт

Синдә иблис!

Мэхмүт

Миндә нишләп булсын?!
Миндә бары хыял сафлыгы:
Язгы ташкын, җәйге яшелләкләр,
Алтын көзләр, карның аклыгы!
Матурлыклар шунда түгелмени?
Урман шаулый, сулар агадыр.
Дөньясында һичбер ямь табалмый,
Гомеркәем үтеп барадыр.
Һәрберсе ширбәт кебек миңа
Тау астында аккан чишмәләр.
Оҗмах шунда дияр идем, әти,
Әгәр «оҗмах кайда?» дисәләр.

Әхмәт

Синдә Иблис! Оҗмах монда! Монда!!
Монда иман! Анда иман юк.
Кешеләрдән кешелеклелек качты,
Яманлыкта утыра яманлык.

Мәхмүт

Мөмкин түгел. Кешелексез халык
Хәйран калдыра алмый дөньяны.

Әхмәт

Кайдан инде сиңа мондый уйлар,
Кем котырта, нинди дошманың?

Мәхмүт

Юк, котыртмый беркем.

Әхмәт

Син алдашма!

Мәхмүт

Юк, котыртмый беркем!

Әхмәт

Алдама.

Мәхмүт

Юк, котыртмый. Алар минем канда:
Каным җырлый, каным уйлана.

Әхмәт

Иблис синдә түгел! Үзең Иблис!
Иблис икән синең каныңда.
Тууыңа тик ул шаһит иде,
Иблис булды синең яныңда.
Ул каныңа кергән. Сине аннан,
Тик мин сине аннан коткарам.
Аны бары мин, каныңнан куып,
Каның белән бергә чыгарам.
Ялтырап китте пычак... Ауды Мәхмүт...
Сүнде хыял — сүнде кайтыр юл.
Соңгы сулыш кына әйтә алды:
«Миндә түгел... Иблис... Синдә ул...»

IX

Көлә Иблис Минә тау башында:
«Ха-ха-ха»сы — таулар өстендә.
Шушы көлү яңгырый иде бары
Әхмәтләрнең өе эчендә.
Ха-ха-халап көлә Бибикамал...
Ә көлүе — көлү идеме?
Шундый хәлгә калды — шундый итте
Мәхмүтенең канлы үлеме.
Ха-ха-халап көлә Бибикамал:
«Кайда Мәхмүт? Кайтып киттеме?
Ха-ха-ха-ха! Берүземе китте?
Ник көтмәде? Әллә көттеме?

Ха-ха-ха-ха!.. Әйдә, кайтыйк, Әхмәт,
Атыңны җик,— ат бар, арба бар.
Балалар да юл буена басып,
Без кайтканны көтеп торалар.
Ха-ха-ха-ха! Әйдә атка китик,
Болыннардан эзлик икәүләп.
Юк, син барма... Әйберләрне төя.
Мәхмүт кайтыр атны йөгәнләп.
Мәхмүт!.. Бар син атны алып кайт! Бар!..
Юк, син барма... Үзем барам мин...
Ком чүленнән ул ат эзләп китте...
Китте . . . .
. . . .

X

Ха-ха-ха-ха!.. Очып барган җирдән
Юл буенда торган бер ташны
Күреп калды Иблис... Шуннан иде
Мәхмүт гомеренең юл башы.
Утырды ул ташка... «Таш бар, юл бар,
Ә кайда,— ди,— кызның кабере?
Үткенчедән хәтта кабер калмый,
Шулдыр инде аның кадере.
Әнә берәү очып үтеп бара
Төн ягыннан Мәхмүт ягына.
Адәм оча хәзер... Биек оча.
Җәяү бармый хәтта хаҗына.
Әхмәт өчен бүләк итеп алган
Җиренең бер чәчкә-үләнен.
Адәм белә, үзе тапап йөргән
Үләннең дә нинди икәнен.
Бер карасаң, юкка исе китә,
Каян кая ташый үләнне,
Бер карасаң, барны бар, дип белми,
Җанлы итеп күрә үлгәнне.

Гаҗәп инде адәм! Әлеге шул,
Төяге бар, туган җире бар.
Шул җир өчен җанын фида кыла,
Нәрсәсе бар? Нинди сере бар?
Нинди сере?» — диде Иблис кабат,
Таш өстеннән кинәт юк булды.
Бар булды ни аңа, юк булды ни —
Төн ягына тотты ул юлны.
Зөя буе менә... Яшел дөнья —
Мәхмүтнең саф, яшел хыялы.
Матурлыкның бармы икән чиге,
Хыялларның чиге буламы?

XI

Гүзәллекләр җиһан кебек чиксез,
Шундый камил, шундый төгәллек.
Мәрхәмәтле җанга яшәү ямьле,
Явызлыкка юктыр гүзәллек.
Иблис өчен берни түгел иде
Бөек Идел, Зөя буйлары.
Кыр эшләре, уҗым яшеллеге,
Җир шатлыгы — сабан туйлары.
Карап торды халык бәйрәменә
Таба алмый мәгънә, берни ямь.
«Тапкан Мәхмүт хыял итәр нәрсә,
Мыжлап тора,— диде,— төрле җан».
Иблис өчен берни түгел иде
Гореф-гадәт, милләт, тел һәм моң.
Әгәр җирдән алар юк ителсә,
Кайгыртыр җан улмы? Улмы соң?
Күңел ача, уйный, җырлый халык:
Монда мәзәк, монда чабышлар,
Монда ярыш, монда йөгерешләр,
Монда көрәш, монда алышлар.
Монда җиңү, монда җиңелүләр,

Монда дуслык, монда мәхәббәт,
Монда яшьлек, монда олпат картлык,
Монда әдәп, монда зур хөрмәт.
Монда күңел, монда халык җаны,
Монда үткән, монда киләчәк.
Монда һәркем туган, һәркем үскән,
Монда яшәп, монда үләчәк.
Иблис өчен болар берни түгел —
Гореф-гадәт, милләт, тел һәм моң.
Әгәр җирдән алар юк ителсә,
Кайгырыр җан улмы? Улмы соң?!
Кешеләрнең дә бит күңелендә
Шатлыгы күп. Күбрәк — мәрхәмәт.
Күңелләрдә Иблис үлә бара —
Искеләрдән калган җәрәхәт
Бетә бара. Яңа заманнарның
Яңа нуры, яңа сулышы.
Кешеләрдә — яманлыклар белән
Яхшылыкның яңа сугышы.
Иблис өчен кунар җан юк монда,
Йөрәкләргә юк бер керер хәл.
Юк булды ул... Аның барлыгын да
Сизми калды хәтта шушы мәл.

XII

Юк булды ул... Азат хәзер ул җир
Элеккеге коллык, җәбердән.
Явызлыкның гаме — яхшылыкны
Кол итүдер бары мәңгегә.
Яхшылыкны җиңсә, Иблис өчен
Бәхет, шатлык, бәйрәм, тантана.
«Бу нинди нур!! — диде Иблис, дертләп,—
Нинди балкыш күзгә ташлана?!»
Ул борылды шунда... Күрә Иблис
Агыйделнең яшел ярында

Яп-ялангач бер кыз басып тора,
Ә беркем юк, беркем янында.
Тирә-якта тантаналы тынлык;
Уйчанлыкта таулар, урманнар.
Шушы минутларда ниндидер бер
Хозурлыкка алар чумганнар.
Кыз яңарак судан чыккан, ахры,
Чәчләреннән көмеш су ага.
Нинди кыз ул? Иблис хәтле Иблис
Һуштан язып аңа ник бага?
Сүзләр көчсез — кызны зифа буйлы,
Су сөлеге кебек дисәң дә,
Иблис хәтле Иблис сылулыктан
Дертләп куйган икән, бүтәнгә
Ни кала! Аһ, кызлар гүзәллеге —
Бар гүзәллекләргә гүзәллек,
Табигатьнең иҗат бөеклеге,
Даһилыгында бер төгәллек?..
Ул су керә... Аны су кызы, дип
Атаргамы икән бу мәлдә?
Урманнарда — ул бит урман кызы,
Ул — тау кызы тауда йөргәндә.
Җил искәндә йомшак Җил кызы ул,
Моның өчен ул гүзәл Җыр кызы.
Айлы төндә якты Ай кызы ул,
Якты көндә якты Нур кызы.
Аннан күзен алалмады Иблис,
Тынып, катып торгач, ахырдан
Телгә килде...

Иблис

Син кем? Син нинди җан?
Юк, син түгел адәм затыннан.

Кыз

Мин — Мәхәббәт! Шушы җирнең күрке,
Шушы җирнең көче, җан-сыны.
Карашларың, буең-сының шомлы,
Ә үзең кем? Миңа әйт шуны?

Иблис

Мин — күк улы!

Кыз

Ялганлама! Беләм,
Мин үземнең беләм күгемне.

Иблис

Беләсеңдер, ә мин — мин түгелмен,
Мин югалттым үзем үземне.
Синең җаның башка... Синдә мин юк —
Явызлыктан азат синең җан.
Шуңадыр да әллә нишләдем мин,
Мин матурлык күрәм, күрәм ямь!
Аһ, җир кызы! Син ни кушсаң миңа,
Мин әзермен шуны кылырга.
Сине Җирнең хакимәсе итеп,
Үзем әзер олтырак булырга.
Син Мәхәббәт икән, син минем дә
Мәхәббәтем булчы гомергә.
Өйрәт мине, өйрәт яхшылыкка,
Өйрәт мине сөя белергә.
«Өйрәт! Өйрәт!» дип ул кызга якын,
Якын, якын килде... Килде дә,
Кочаклап бер үпмәкчеме булып,
Тотып алгач кызның биленнән,
Кыз тайпылып, ачу катыш бары
Караш ташлау җитте — чатырдап
Яшен атты, күк күкрәп куйды,
Купты давыл яшен артыннан.

Кара болыт басты Кояш нурын,
Тетрәп торды таулар, урманнар.
Җиргә ятып үксеп елагандай,
Сыендылар җиргә үләннәр.
Син кагылма, Иблис, дигән кебек,
Йөрәгемә минем, җиремә,
Аны күккә очырып алып китте,
Бөтерелеп көчле өермә.
Тынды давыл, балкыды җир һәм күк,
Хозурлык, ямь итә тантана.
...Кыз яңарак судан чыккан, ахры,
Чәчләреннән көмеш су тама.

XIII

Килде Иблис таулар арасына...
Таулар өнсез, таулар горурлар.
Иблистә тәү теләк туды шунда
Таудай тыныч, горур булырга.
Ә барыбер таулар зыңлый иде,
Сер бар иде таулар зыңында.
Гүя, алар сөйләшәләр иде
Үз телендә — таулар телендә.
Кавказ! Кавказ! Гүзәлләкләр иле,
Лачыннар һәм җырлар иле син.
Батырлыклар, тугрылыклар иле,
Матурлыклар, кызлар иле син.
Егетләрне — егет, ирләрне — ир,
Имамнарны — имам иткән ил.
Хәнҗәр-кылыч, канлы сөю белән
Җил-давыллар, утлар үткән ил.
Таулар өнсез. Таулар тыныч кебек,
Тыныч иде Гуниб тавы да.
Бу мәһабәт тынлык арасында
Ярсу Кара-койсу шавы да

Берни түгел... Тауда аккан сулар
Үтә ярсу, үтә шаулылар.
(Тауларыдай тыныч, суларыдай
Шаулы төсле кайчак таулылар.)
Утыра Иблис Гуниб тау башында...
Кайчандыр шул ташка утырып,
Бер генерал (аның фамилиясен
Кем соң белә? Хәтер туздырып,
Кем соң бүген аны искә алсын)
Кабул иткән әсир Шамилне.
(Шул турыда ташта язу тора:
«Фәлән көнне әсир ителде...»)
Таш тирәли каен агачлары...
Ни өчендер алар ак түгел.
Кайгылардан карайдыгызмы? — дип,
Каеннардан сорау ят түгел.
Теге генералдай кукыраеп
Утыра торгач, Иблис җилкенде:
«Нигә әле минем әсирем юк,
Әсирем юк Шамил шикелле?
Нигә юк ул? Нигә әсирем юк?!
Мин бит аны Шамил эзеннән
Калугада яшәтмичә генә
Мәккәнең бит туры үзенә
Алып китәр идем... Аңа анда
Туп-туры юл ята оҗмахка.
Нигә әле оҗмах — хыял өчен,
Хәтта әсир, корбан булмаска?
Тау сукмагы буйлап күтәрелә
Икәү әнә — ике әсирем.
Мин аларның йөрәгенә агу
Саламын да... Аның тәэсирен...»

XIV

Ә ул икәү — яшь егет һәм яшь кыз...
Кубыз иде егет кулында.
Егет җырлый... Нәрсә булсын инде
Ике яшь йөрәкнең җырында?..
«Ике йөрәк — ике якты язмыш...
Бер кубызның ике кылыдай...
Язмышлардан безнең узмышлар бар...
Долалай, долалай, долалай...»
Ике йөрәк өчен бер җыр иде
Бер йөрәккә җәйгән тамырдай.
Тау артында, бәлки, башка җырдыр,
Ә мондагы исә: «Долалай!..»
«Долалай» дип кушылдылар җырга
Тирәдәге кара каеннар,
Таулар, ташлар һәм тау чишмәләре,
Туганнар һәм дуслар, якыннар —
Барысына уртак бер моң иде
Барсы бергә алар бер бөтен.
Шул бөтеннән кемне аерып алып,
Әсир итеп кара... Юк! Читен!
Әсирме соң Шамил? Йөрәк кабул
Итәме соң әсир диюне —
Әсир итеп буламы соң җирне,
Халыкны һәм җырны, сөюне?
Әсирлекне зурлап торса да ул
Иске язу Гуниб ташында,
Генераллар түгел, хәтта Иблис
Көчсез иде сөю каршында.
Кыз һәм егет — бәхет әсирләре...
...Батты кояш. Күктә тулган ай.
Китте Иблис. Калды тауларда җыр...
«Долалай, долалай, долалай...»

XV

Онытылган кайчак искә төшә,
Югалган да кайчак табыла —
Юлы төшеп килеп чыкты бер мәл
Бер якташы Әхмәт янына.
Шыр ялангач өйдә япа-ялгыз
Каршы алды Әхмәт якташын.
Чәч агарган... Йөз агарган... Гүя
Мәккәнең ул ят бер ак ташы.
Кунагына Әхмәт сөенмәде,
Булмады бер сүзе, теләге,
Әдәп белән нәфрәт арасында
Янды бөтен тәне, йөрәге;
Кабул итте әдәп саклап кына
Килгән бүләкләрне ерактан.
Кунак китте, тик ниндидер хуш ис
Аңкып калды кебек кунактан.
Нинди ис ул? Ул таныш та төсле...
Кайдан аңкый соң ул, кай төштә?
Төргәкләрне ачты,— ул ни күрсен! —
Төргәктә бер бәйләм мәтрүшкә...
Мәтрүшкәне исни-исни Әхмәт
Күзен йомды... Битен каплады.
Кайда Әхмәт? — Тартып алды аны
Ерак калган туган яклары.
Кайда Әхмәт? — Әнә читән буйлап,
Бала чагы килә йөгереп.
Кем соң әле? Улмы соң — ул?
Егет булып җиткән өлгереп.
Кайда Әхмәт? Аның колагына
Ниндидер сер сөйли чишмәләр,
Оҗмахтамы ята күккә карап,
Бибикамал җыя чәчкәләр.
Кайда Әхмәт? Биби гөлләрендә
Яшьлек тыны, яшьлек хисләре.

Болыннарда кемдер чалгы яный,
Аңкый яшел печән исләре.
Әкрен генә тирбәләләр төсле
Дулкыннарда басу иңнәре.
Кайда соң ул? Кая илтә җилләр,
Кая очыра язмыш җилләре?
Әллә җирдә, әллә күктәме ул?
Калдымы ул булып дәр-бәдәр *.
Кайда Әхмәт? Нәрсә арбады соң
Аның җанын бүген шулкадәр?
Кайда Әхмәт? Нинди сихри хәл бу?
Өндәме ул әллә төштәме?
Мәтрүшкәгә, гүя туган җиргә,
Тамды аның тәү күз яшьләре.
Елый иде Әхмәт... Әхмәт елый...
Йөрәгендә иде ут-яшен.
...Минә тауда Иблис, көлә-көлә,
Түгә утлы, әче күз яшен.

* *Дәр-Бәдәр* — йортсыз-җирсез (гарәпчә).

ТАТАР КАНЫ

Поэма

Йөрәк каным белән яза-яза,
Теркәп килдем елга елларны.
Ни белән соң мин язарга тиеш
Канга бәйле шушы юлларны?
Кан... Кан... Ул — җан,
йөрәк,
сулыш,
тормыш —
Мөкатдәсләрдән иң мөкатдәс!
(«Кан-җан» — үзе рифма! — ә русларда
Туры килә аңа «мәхәббәт» *.)
Бар изгелек сыны, әйе, ул кан!
Канга бәйле якын туганлык.
(Кан кардәшлек мәңге яшәп килгән)
Канга бәйле авыр дошманлык.
Кан дошманлык — инде үткән заман,
Алар безгә керми киткәннәр:
Заман җилендә шул җилгәрелеп,
Киләчәккә бара үткәннәр.
Кан дошманлык түгел, ә кан дуслык
Яши хәзер кеше канында.
Йөрәгемне ярып төшкән җырым
Әнә шундый дуслык хакында;
Ул дуслыкның туган Ватаны бар.
Тирән тамыр җәйгән җире бар.
Ул дуслыкның сүзсез сөйләшерлек
Кан теле бар, йөрәк теле бар.
Шагыйрь диләр мине... Димәк үзем
Сөйләшә алам каным белән дә,
Кирәк икән бәхәсләшә алам

---

* «Кровь» — «любовь».

Үз каным һәм җаным белән дә.
Шагыйрь диләр мине... кануннардан
Азат минем гади мәртәбәм.
Мин азатмын алтын йөгәннәрдән,
Мин азатмын алтын тәртәдән.
Әйтерләр: «Бу нигә болай түгел,
Ә тегеләй нигә тегесе?»
Шагыйрьләрдән мотлак күп беләләр
Өстән бакканнарның күбесе.
Шагыйрь диләр мине... хокукым юк
Хакыйкатькә хыянәт итәргә.
Мин бурычлы шушы юлларымны
Шагыйрь намусы белән үтәргә.

I

Җитерсәгез икән күз алдына
Сандугачлы җәйге бер таңны,—
Шушы таңның һәрбер минутыннан
Җиргә, җанга чыңлап моң тамды.
Шушы таңның бетмәс хозурлыгы
Йөрәкләргә иде мең шифа.
Шушы таңда тәү кат ана булды
Татар кызы Зифа, Гөлзифа.
Бала табу йорты. Җошлар белән
Бергә сайрый төсле сабый кыз.
Яшь лейтенант — ата — чик буенда
Икеләтә бүген йокысыз.
Эчтән генә: «Зифа бәгърем, диде,
Җотылгандыр инде баладан...»
...Кинәт шартлау... һәм җир тетрәп куйды,
Гүләү тавышы килде һавадан.
Бар дөньяның асты өскә килде —
Ут эченә керде туар көн.
Тәүге минутта ук чолгап алды
Бөтен тирә-юньне ут-төтен.

«Иван! — диде яшь командир Яхин,—
Приказ түгел, бары үтенәм.
Чап роддомга, зинһар коткара күр
Ана һәм сабыйны үлемнән.
Моннан миңа китүләр юк, солдат,
Хәзер бу җир сугыш яланы.
Озат тылга. Күр, әнә, бомбага
Тота башладылар каланы...»
Чапты Иван! Таңга каршы чапты...
Яңа кала. Килсә — ни күрсен! —
Җимерелгән бала табу йорты,
Бала табу йорты ут-төтен.
Ак халатта я булмаса эчке
Күлмәктәге көе хатыннар
Сабыйларны өч-дүртәрен бергә
Өй эченнән тышка ташыйлар.
Ир тавышы: «Машинага! Җәһәт!»
Кайда Зифа? Йөрде җан атып,
Күрде аны — кан эчендә, һушсыз.
Носилкада. Барды озатып.
Кире чапты Иван. Кире чапты
Командирга хәбәр итәргә.
«Алар тере. Тылга китте»,— дигән
Бәхетле сүз — шатлык илтергә.
Килде Иван... Ах! Командир үлек...
Катып калды баскан җирендә.
Сугышның бу тәүге сәгатьләре
Күнегелмәгән шул үлемгә.

*

Язмыш мине шаһит итмәсә дә
Тәүге сәгатенә сугышның,
Ә Берлинда җаным-тәнем белән
Кичердем мин соңгы минутын.

Тәүге белән соңгы арасында
Миллионлаган гомер, язмышлар.
Кайтмадылар күпме туганнарым,
Күпме дуслар, күпме танышлар.
Миллионлаган язмыш арасында
Геройларым да дүрт исемле.
Ләкин алар болындагы сансыз
Үләннәрнең дүрте шикелле.
Ә берсен бит тәүге минутта ук
Чабып өзде үлем — ут-чалгы.
Бүтәннәре сугыш юлларында
Бер табылып, я бер югалды.
Һушына килгәч, Гөлзифа да кинәт
Аңламады кайда ятканын.
Тик соңыннан белде тере калган
Сабыйларның ары киткәнен.
Беркөнлекләр, өчкөнлекләргә дә
Сугыш — сугыш иде... Кансызлык...
Зифа — ана, тик баласыз ана,
Күкрәк сөте акты кан булып.
«Кайда бала? Мөмкинме соң тере
Калулары мондый дөньяда?..»
Күңел кошы булып кына калды
Үз сабые безнең Зифага.
Тере калды Зифа... Аһ, ул кеше җаны,
Үлгән җирдән кайта, терелә.
Үлгән, диде тере баласын ул,
Тере, диде үлгән иренә.
А, ышану! Ярый әле ул бар!
Ә соң ансыз яшәү мөмкинме?
Зифа — доктор. Яу кырына китте
Ирен эзләп киткән шикелле.
Яу кыры киң. Шушы киңлекләргә
Утлар аша җиргә багу да,
Челпәрәмә килгән бу гомернең
Ватыкларын эзләп табу да

Бәхеттер ул сөйгән йөрәкләргә,
Өмет белән тулы йөрәккә?
Гөлзифага бар дөресне әйтсәң,
Ышанмас ул. Минем күкрәккә
Ятып бер елар да: «Юк! Юк! — дияр,—
Дөнья түгел газап бөтие.
Сөям аны! Мөмкин түгел аның
Мәхәббәтне ташлап китүе!»
Зифам! Зифам! Синең тойгыларга
Кысыласым килми, килми шул!
Үлгән һаман синдә тере көе,
Тере балаң һаман үлгән шул.
Аналык бит сиңа бер күз ачып
Йомган ара гына, Гөлзифа.
Кем уйлаган шушы кыска ара
Булыр диеп сиңа мең җәфа?
Әй укучым, син дә мине кичер —
Язганнарым таныш тоелса.
Китте күрү тормыш, сугышны да
Әзер сценарий буенча.
Мин солдатмын. Һәр солдатның яуда
Үз язмышы һәм үз сугышы.
Сулышлар да ул бертөрле кебек,
Тик үзенчә һәркем сулышы.
Сугыш өчен болар барысы да
Гади тарих, гади күренеш.
Бер карасаң, сугыш тормыш иде,
Гади тормыш — үлем, үтереш.
Гади тормыш иде ышанырлык,
Ышанмаслык хәлләр сугышта.
Менә ялан госпитале... Ул да
Үз тормышы белән тормышча.
Кемнең кулы, кемнең аягы юк,
Кемнең башы, йөзе канлы бинт.
Гөлзифага берәү пышылдады:

«Зифа, это вы? Вы-ы... Бу сез бит!»
(Бөтен йөзе иде канлы бинт).
Ни әйтергә белми катып калды,
Катып калды Зифа... Соңыннан:
«Кем син?» — диде аңа. Әмма солдат
Язган иде инде һушыннан.
(Әй син, тормыш, язмыш!.. Менә әле
Бу юлларны язган чагымда,
Телевизор аша, сыер савучы ир —
Яп-яшь бер ир туган ягымнан
Карый миңа. «Хезмәт даны» дигән
Өч орденлы. Карый һәр йортта.
Әй заманнар! Герой булып була
Безнең көндә сыер савып та.
Ә лейтенант? Минем яшь командир?
Кайда аңа дан һәм батырлык?
Хәбәре дә хәтта килмәде бит
Ил-җирендә балкып ятырлык.)
«Кем ул,— диде Зифа.— Юк, ул түгел,
Тавышы да түгел таныррлык».
Шул вакытта хирург: «Кан! Кан! — диде,—
Каны беткән аның, каны юк!»
Солдат белән янәш ятты Зифа —
Тәннән тәнгә күчә, күчә кан.
Әй гомернең бөек минутлары!
Тәннән тәнгә күчә, күчә җан.

Мине шагыйрь диләр... Бу минутта
Көчсездер ул хәтта шагыйрьлек.
Табалмамдыр канлы сүзләрне мин
Канлы шигырь яза алырлык.
Җир өстеннән гүя юар өчен
Газапларын сугыш кырының,
Гомер булып рус егетенә
Каны керә татар кызының.

Нәрсә соң бу? Әйе, гадәти хәл,
Гадәти хәл тәүге күрүдә:
Бер уйласаң, гадәти бит җирдә
Бала табу — гомер бирү дә.
Ә соң анда күпме бөеклек бар —
Кеше туу — нинди бөеклек!
Шушы бөеклекне кыйратырга
Туган сугыш — нинди киеклек!
Кыйралышта күпме корал һәм ут,
Ә ут сүнә кеше тәнендә,
Үз акылы алдында бит адәм
Кала үзе бөҗәк хәлендә.
Ә син, адәм! Синең бөеклегең
Вәхшилеккә гүя юл суза.
Вәхшилекне каны белән җиңәр
Өчен дә шул ята Гөлзифа;
Яралыга аның каны керә,
Ул кан исә яшәр юл кебек.
Үзенең дә гомере — бу сугыш бит! —
Өзелергә торган кыл кебек.
Бүген син бар, ә иртәгә инде,
Ә иртәгә инде... Кем белә...
Әмма исән калырмын, дип яуда
Өметләнми кемнәр? Кем генә?
Бүген монда, ә син уйламыйсың
Барыр юлың күпме калды дип.
...Озатып калды яралылар белән
Киткән Гөлзифаны алгы чик.
Тәү сәгать үк эшелонга килеп
Ябырылды соры юнкерслар.
«Воздух!» диде Зифа һәм кычкырды:
«Ләгънәт сезгә, һай, кан эчкечләр!
Нишлисез сез? Монда яралылар,
Яралылар монда бaралар.
«Боах!» «Боах!» Бомба... Ишетелеп калды:
«Доктор! Доктор!»... шартлау аралаш.

Кан эчендә җирдә ята Зифа,
Ала Зифа соңгы сулышын...
Үлмә, Зифа, зинһар, үлә күрмә.
Башлана гына синең тормышың!
Үлмә, Зифа, синең кызың тере,
Болай да бит бала атасыз,
Нигә тагы ул калырга тиеш,
Ул калырга тиеш анасыз?
Зифа өчен кан коелыш бетте...
Яңак буйлап каны йөгергән.
Кичә —
Каны белән гомер биргән иде,
Бүген — язды үзе гомердән.

II

Госпитальдә дә бит тормыш — тормыш...
Кызык инде солдат гомере.
Бүген һушсыз, ә иртәгә дисәң —
Күтәренке аның күңеле.
«Иван! — диләр.— Бие, сиңа бүләк!
Түбәң синең күккә тиячәк».
«Аяк юк»,— ди Иван. Ә тегеләр:
«Сиңа шуннан аяк үсәчәк».
«Хәл керсен,— ди Иван,— биергә ул
Мин риза хәтта баш белән».
«Да!.. Ха-ха-ха! Кем биемәс икән
Менә шундый кара каш белән!»
Күреп тора Иван: фотосурәт...
«Каңгыртмагыз, нинди бүләк ул?»
«Хирург бирде. Сиңа гомер биргән,
Үзе һәлак булган йөрәк ул».
Алды Иван. Карап катты Иван...
Күзләреннән мөлдерәп яшь ага.
Караштылар дуслар. Менә сиңа
Көлке, диештеләр үзара.

Елый Иван, үксеп-үксеп елый,
(Ни әйтергә моңа карата).
Иван белән бергә елый әле
«Ха-ха!» дигән бөтен палата.
Нинди халык соң бу? Аңлап кара
Аның җанын, холкын, сулышын.
Ничек итеп Гитлер шул халыкны
Кол итмәкче булган икән соң?

III

Яу кырында яраланып, тере
Калу үзе бәхет саналды.
Ул бәхеткә бөтен үткәннәр һәм
Бар киләчәк килеп ялганды.
Бәхетне дә, бәхетсезлекне дә
Ялгый-ялгый еллар үттеләр.
Ә ул еллар киләчәкләрне дә
Ага-ага үткән иттеләр.
Хәзер инде, сугыш елларыннан
Ераклашкан саен аралар,
Яуда үлүләр дә тирән эзле,
Тирәнәя алган яралар.
Ул яралар безнең Иванда да
Калмадылар алган көенчә.
Иван язмышы соң ничек, дисәк,
Һәркемнең ул һәрчак үзенчә.
Ә шулай да кем соң әле Иван?
Ә кирәкме аның кемлеге?
Суздаль ягындагы бер авылда
Кырыктылар аның кендеген.
Буе-сыны, төсе-башы белән
Коеп куйган саф рус егете.
Андыйларга бик тиз багланыла
Кыз-кыркыннарның да өмете.

Армиягә алгач, юллар аны
Китерделәр илнең чигенә.
Ул Яхинга ординарец булды,
Командирга — Зифа иренә.
Ә аннан соң?.. Утлы өермәнең
Безгә таныш бөтен михнәте.
...Кайтты Иван култык таягында,
Ә кесәдә Зифа сурәте.
Ике тәрәз арасында, түрдә
Тора Зифа — күзләр нур чәчә.
Татар кызы — почмактагы тәре,
Мәрьям-ана белән янәшә.
Ике ана — берсе легендадан —
Алланың бит үзен тудырган.
Икенчесе — ике гомер биреп,
Һәлак булган сугыш кырында.
Карлыгачның пар канаты — кашлар,
Өтеп ала торган карашлар.
Шул караш та төйнәлгәндер төсле
Төрле язмыш, төрле тарафлар.
Кергән, чыккан һәркем Гөлзифаны
«Чегән кызы бит бу!» диделәр.
Иванның да озак өйләнмәвен
Гөлзифадан гына күрделәр.
Ә кем белә, бәлки, биргәндер ул
Иванга көч, дәрман, сабырлык.
Мәрьям-анадан да көчлерәктер
Мәрхәмәтлелек һәм матурлык.
«Өйләнүләр качмас,— диде Иван,—
Кирәк әле башта җиңәргә.
Киләчәкләр бүгенгедәй булмас,
Ә хәзергә сыер җигәргә...»

Килде Җиңү! Еллар... Институт...
Әйтте Иван: «Кайтам — җан куша!»

Иван белән килен булып төште
Кала кызы Марфа, Марфуша,
Зифаны тәү күргәч, яшь Марфада
Томанлы бер зур шик яралды.
Тик язмышын ире сөйләп биргәч,
Күңелдәге томан таралды.
«Нигә Зифа кызына,— ди Марфа,—
Син ата, мин ана түгелмен?»
(Яшь Марфада авыр түгел күрү
Булачак яшь ана күңелен.)
Бу сораудан өзгәләнде Иван:
«Кайдан миндә шундый гамьсезлек?
Бу түгелме,— диде,— үз җаныңа,
Үз каныңа булган кансызлык?»
Әйтеп куйды: «Ул баланы табу —
Хыял эчендәге хыяллар.
Ә түгелме Зифа туганнары
Минем белән синең туганнар?
Ник шуларны эзләмәскә безгә?
Туганнары бардыр...» Бар ул, бар!
Кайда алар? Ә бит җир йөзе киң,
Кайда да бит яши татарлар?!
Бөтенесе өскә бәреп чыкты,
Тынычлыгы качты Иванның.
«Мин табарга тиеш,— диде эчтән,—
Туганнарын минем дөньямның.
Тусак та без төрле-төрле җирдә,
Без бит бер кан хәзер — без бер кан!»
О туганлык! О мәхәббәт уты!
Сүнүләр юк, син бер кабынсаң!
Китте хатлар бөтен илне иңләп...
Язам,— дисәм,— барын җентекләп,
Мәрхәмәтле бу газабы аның
Булыр иде үзе бер китап.
Җентекләүгә проза бурычлыдыр,
Поэмага ул бер кан дошман.

Күпме билгесезлек, күпме серләр
Ачылмыйча кала сугыштан.
Кайда татар — шунда хатлар китте...
Юлын тапты Казан, Уфаның,
Ленинградта я Мәскәүдәдер
Туганнары, диде Зифаның.
Язды Әстерханга, Саратовка,
Оренбурга, Пермь, Пензага,
Чиләбегә, Рязань, Свирлауга...
Булырмы ул, булмасмы дип һәр көн
Тотты кебек Иван шобага.
Кай җирләргә генә бармады ул,
Өнсез яткан хатлар эзеннән.
Төмән, Тобол буйларына барып,
Урап кайтты ерак Себердән.
Кайда татар — уе шунда китте,
Өтте аны хәтер-яралар.
Тик Марфуша әйтте: Русь җирен
Ничек басып алган татарлар.
Күңеле белән Марфа беркатлы шул,
Тик елмаеп куйды Ванюша:
«Миндә татар каны, мине дәме
Татар басып алган, Марфуша?»
«Синдә татар каны,— диде Марфа,—
Синдә татар каны! Ха-ха-ха!
Болай булгач, чынлап, Иван җаным,
Син татарник Иван лабаса!»

«Көлмә, Марфа!.. Аера бел син дә
Дөреслектән бөтен ялганны!
Татар каны бизәп һәм гүзәлләп
Тормыймыни Кызыл мәйданны?»
Аңламады Марфа: «Кан һәм бизәү...
Нинди була ул кан бизәве?
Җиргә тамган кан ул карая бит,
Кара тап соң матур, гүзәлме?»

Әйтте Иван: «Димәк, кара түгел,
Храм * бит балкый Кремль янында,
Бөек җиңү истәлеге булып
Басып тора татар канында.
Ә ул чәчәк бәйләмедәй гүзәл
(Татарник та үзчән бер чәчкә).
Тарих тарих булып калсын, аңа
Киңәш бирер идем тимәскә».
«Тарих — тарих та ул,— диде Марфа,—
Җуеп булмый барын — хәтер бар.
Үткәннәргә ничек карыйлардыр
Синең кебек татар канлылар?»
«Юк, мин рус бит,— диде Иван,— мин рус!
Коткарса да ул кан үлемнән.
Рухыбыз бар, данлы халкыбыз бар,
Мөмкин түгел китү үзеңнән.
Тарихыбыз һәм халкыбыз данлы,
Җиңеп чыккан һәрбер сугыштан.
Һәрбер җиңү, яулап алган җирләр
Тик Рус дәүләтен бит ныгыткан».
«Безнең заманда да үз дәүләтен
Ныгытырга, Ваня, бик теләп,
Синең кебекләрне,— күпме корбан! —
Кул-аяксыз итте бер үләт.
Ныгытулар булсын иде һәрчак
Җирдә берни кырмый, яндырмый,
Башкаларны җирсез, моңсыз, телсез,
Кул-аяксыз, сукыр калдырмый».
«Син, Марфуша, шәйләп! Киңәш бирәм
Мәсьәләгә тирән кермәскә.
Татарник бит чәнечкеле чәчкә,
Кирәктер ул аңа тимәскә!»

* Сүз Василий Блаженный храмы турында бара.

Иван! Иван! Нигә «шәйләп!» дисең,
Марфага син, зинһар, шик салма.
Шуннан да зур бәхетсезлек юктыр,
Эшең, уең булса ясалма.
Ваня! Ваня! Шагыйрь диләр миңа,
Кукрәп була бары яшьнәсәң.
Ни мәгънәсе бардыр шагыйрьлекнең
Әгәр дә гел шәйләп яшәсәң?
Шагыйрь диләр миңа. Мин иң тәүдә,
Мин иң тәүдә, димәк, миллимен.
Милләтем һәм халкым белән генә
Мин шагыйрьмен, Туган иллемен.

Һәр халыкның, һәр милләтнең җирдә
Үз тамыры һәм үз кәүсәсе
(Кеше бөек акыл, җаны белән,
Бөек итми аны гәүдәсе).
Ул ботак та, ул яфрак та түгел.
(Көмеш, диләр, суда эремәс!)
Ботак кебек бик тиз корымас та,
Яфрак кебек коелып черемәс.
Кайберәүләр әйтә: үткәннәргә
Керү нигә — буш һәм вакытсыз.
Аларча бит яшәп була хәтта
Милләтсез һәм туган халыксыз.

Ваня! Марфа! Ә сез андый түгел —
Үткәнеңне кирәк белергә.
Халкың белән горурлану — ул дан!
Тик кирәкми аны (нигә ул сан?)
Зурга, бәләкәйгә бүлергә?
Марфа! Марфа! Син гаепле түгел,
Әгәр синдә булса хаталар.

Рус җирен бит, җаным, беркайчан да
Басып алмадылар татарлар.
Канын татар койса койды бары
Саклап илен, туган җир-суын.
Бүген исә дуслык каны тибә
Ирең йөрәгендә, сылуым.

IV

Тырышканда мөмкин булган кебек
Ташларга да кадак кагарга,
Печән кибәненнән энәне дә
Мөмкиндер ул эзләп табарга.
Күңелемдә янган тойгыларым
Түгелдер ул ким дә, артык та,
Дертләп китте Иван: журнал бите —
Детдом балалары «Артек»та.
Әй елмая, әй елмая шуннан
Бер кыз бала карап Иванга.
«Таптым! — диде.— Һәй! Эврика! Марфа!» —
Сикереп торды Иван диваннан.
Әй елмая бала... Көләч иде
Командиры — Зифа ире дә:
Командирга суеп каплаган бит —
Охшап тора бөтен җире дә.
Мәрхәмәтле йөрәк тибешләре,
Сез бар чакта минем җырым да
Канлы кебек һәм канатлы кебек...
...Очты җәһәт Иван Кырымга.
Очмаслыкмы? Ниндидер көч, тою
Керәдер ул кеше канына.
Кыз бала да чакыра кебек иде:
«Кил! — дип,— кил! — дип,— минем яныма.
Әй чакыру! Күңел чакыруы!
Каршы килү аңа мөмкинме?
Табылырмы, юкмы? Нинди детдом?

Ә кыз бала шулмы, түгелме?
Менә диңгез... Безнең Иван исә
Я тегендә чапты, я монда.
Җешеләрне язмыш йөртә, диләр,
Язмыш иде бала — Иванга.
Менә, менә ябылырлар кебек
Йөрәктәге бөтен яралар.
Белде Иван: Мәскәү детдомыннан
Җилгән икән теге балалар.
Кызның кайдан, кем икәнен белгәч,
Батты Иван авыр уйларга.
Язмышлардан узмыш юк ул, диләр,
Кем уйламый аны узарга.
Шуңадыр да: «Үзен күрәм! — диде,—
Шайтан гына, диләр, өметсез:
Мәскәү бөек, мәрхәмәтле мәркәз
Ул мине дә итмәс бәхетсез».
Кызыл мәйдан аша ул җитәкләп
Үтәр кебек иде шул кызны.
Мәйдан аша үтеп бара Иван...
Үтеп бара... Әмма ялгызы.
Бу мәйданда бөтенесе изге —
Тарих монда аның һәр ташы.
Тора монда тугыз башлы храм —
Мин, дигәндәй, җиңү патшасы.
Бу мәйданда бөтен нәрсә изге,
Шуларга без инде өйрәнгән.
Монда күпме гомер һәм язмышлар
Бер төенгә килеп төйнәлгән.
Бу мәйданда бөтенесе изге,
Ята кебек һәр таш уйланып.
Русь бу! Бу рус җире! Һәр сулышы
Иманына яши инанып.
Әмма монда, барсыннан да башка,
Мавзолей бар, димәк Ленин бар.

Гомер юллары бит башта Казан,
Уфа, Себер аша ятканнар.
«Үткәннәр дә, бүгенге дә монда
Янәш тора. Тора! Хакыйкать!
Кайнап торсын өчен тора алар
Бөек дуслык дигән хәрәкәт.
Ваня, син дә барысына: «Миндә
Татар каны бар,— дип карама.
Безнең заман — канга кан кушылып,
Дуслык чәчкә аткан замана.
Син торасың басып, синең янда
Мин дә торам — әмма сабырмын.
Миңа шагыйрь диләр, кызны, Иван,
Син тапмасаң, ул мин табармын,
Икебез дә сабыр булыйк әле,
Син яши күр төрле үгетсез:
Ул кыз тере, Ваня, ул кан тере! —
Безнең яшәү түгел өметсез.

ЭЧТӘЛЕК

Авыл көе . . . 5
Синең нинди улыңмын мин? . . . 6
Сиңа барам . . . 7
Бер гомер җитми икән . . . 7
Яшел көз . . . 8
Кайда булдым?.. . . . 9
Уфа юкәләре . . . 10
«Көз. Төн. Яңгыр...» . . . 11
Имән төбендә . . . 11
Яз төсендә . . . 12
«Гомер башы...» . . . 12
«Рәхәт миңа...» . . . 13
Күк чәчкәләр . . . 13
Туу . . . 14
Икмәк һәм шәрап . . . 15
Плащ-палатка . . . 16
Син гомергә яшьтәш . . . 16
«Дусларым бар...» . . . 17
Бүдәнә белән тартай . . . 18
Алаша . . . 19
Якты көздә . . . 20
Әтиемә . . . 20
Бу җирләрдә . . . 22
Шадра пәри . . . 23
Нишләр идең? . . . 24
Аңламассың бу дөньяны . . . 26
Татар теле . . . 27
Париж өстендә . . . 28
Бар! . . . 30
Казанның татар зиратында . . . 31
Татар бугазы . . . 32
Янган йорт . . . 33
Ялгызлык . . . 33

«Бәхеткә дә, рәхәткә дә...» . . . 34
«Барысы да соңлап килде...» . . . 34
Ак каеннар . . . 35
Гаҗәпләнделәр . . . 36
Анна Ахматовага . . . 37
«Каләм алсам...» . . . 39
Шигырь . . . 39
Мәхәббәтнең килгәнен мин тоям . . . 40
Әдәпсезлек . . . 41
Ике таш . . . 42
Кичер мине . . . 43
Булгандыр бит... . . . 44
Чит тел аша... . . . 45
Беренчесе . . . 46
Хәтерләү . . . 47
Алар өчәү иде . . . 48
«Татарлардан руска...» . . . 49
Туган шигърияткә . . . 50
Яу кырлары . . . 51
Иртә төшкән кар . . . 51
Гомерлектер ул... . . . 52
«Их, ичмасам...» . . . 52
Бу җырлардан синсез китмимен мин . . . 53
«Ачылмаган сер ул...» . . . 53
«Мине күрсәң...» . . . 54
Кызлар өчен . . . 54
Берәүнең берәвенә . . . 55
«Шатланыр, дип син...» . . . 56
Яфрак . . . 57
Өйләрендә утлары бар . . . 57
Сиңа тагы мин бер киләм әле . . . 58
Яшь бер гамь . . . 59
«Үзем сиңа гел үпкәләп барам...» . . . 60
«Син бәхетсез...» . . . 60
Күзге кояш . . . 61
Әллә ниләр әйтер идем сиңа... . . . 61
Миңеште . . . 62
Эзләмим . . . 63
Васыять . . . 64
Иске елны озатканда . . . 65
Мин озатам... . . . 66
Кичә үлсәм . . . 67
Күккүк тавышы . . . 68
Таң алдыннан әйтелгән шигырь . . . 69
Гармун . . . 70

«Бер вакыт та ялгыз...» . . . .
Нинди көн бу?.. 73
Гармунчы кыз 74
Кичәге хәлдән соң дуска әйтелгән сүз 76
«Төн уртасы...» 77
Юкка түгел, юкка түгелдер 78
«Дөньяда сер бетеп бара сыман...» 79
Соңгысыдыр кебек 79
«Кылган эшләр төрле...» 80
Дуртьюллыклар 83
Иблис. *Поэма* . . . .
Татар каны. *Поэма* 125

Назар Наджми
(Назмутдинов Назар Назмутдинович)

ИДУ К ТЕБЕ

Стихи и поэмы

(на татарском языке)

ИБ № 5481

Редакторлары *Ф. Зөлкарнәев, Х. Әюпов.* Художнигы *Ш. Насыйров.* Художество редакторы *Ф. Хәсьянова.* Техник редакторы *С. Әхмәтҗанова.* Корректоры *М. Мирсалихова.* Җыярга тапшырылды 12.11.87. Басарга кул куелды 5.02.88 ПФ 09030. Форматы 70×108¹/₃₂. Типогр. кәгазе № 1. Гарнитурасы «Литературная» Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 6,3+рәс. 0,1. Шартлы буяу-оттиск 6,6 Нәшер-хисап табагы 5,8+рәс. 0,05. Тиражы 4000 экз. Заказ Р-589. Бәясе 70 тиен Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

ПРОВЕРЕНО
07 СЕН 2016
Подпись

70 тиєн